Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 51 (1416) 30 декабрь 2022 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

11

Хәзерге көндә Каюм Насыйри музее күренекле мәгърифәтче кайчандыр үзе салган йортта урнашкан.

12

Яңа елны ничек карышыларга, Куян елыннан ни көтәргә һәм нәрсәдән сакланырга – йолдызнамә җавап бирә.

16

Чуашлар үзләрен болгарларның дәвамчылары дип атарга ярата, тик күп дәлилләр моның бәхәсле булуын раслый.



Яңа елда гел искечә калсын
Бары игелекле эш-гамәл!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- «Казан Кремле» музей-тыюлыгының Ислам мәдәнияте музеенда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең 140 еллыгына һәм дин белгече, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Барудиның 165 еллыгына багышланган «Үзгәрешләр чоры мәдрәсәсе» күргәзмәсе ачылды.

- Мәскәү шәһәре мөселманнары Диния нәзарәте съездында Илдар хәзрәт Галәветдинов янә бертавыштан нәзарәт рәисе вазыйфасына сайлап куелды.

- Язучы Әхәт Мушинский Рус ПЕН-үзәге тарафыннан гамәлгә куелган Фазил Искәндәр исемендәге Халыкара премия лауреаты булды.

- Казанның Лобачевский урамында урнашкан каһвәханәдә «Шигырь һәм каһвә» дигән яңа шигъри проект башланып китте.

- Уфаның Дан бульварындагы скверга ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гәрәев исеме бирелде.

- «Татарстан» телерадиокомпаниясендә Заһир Бигиевнең «Зур гөнаһлар» әсәре буенча эшләнгән радиоспектакль премьерасы булды.

- Татар китабы йортында Шәриф Камалның вафатына 80 ел тулган көнне беренче тамашачыларга «ВӘХЕТ JЬLЬ» (Бәхет елы) спектакле тәкъдим ителде.

- Казан дәүләт циркында гыйбадәт бүлмәсе ачылды.

- Juna музыкаль төркеме шагыйрь, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Әхмәтҗановның шигырьләренә язылган «Afsen» («Сихер») мини-альбомын чыгарды.

- Театр әһелләре берлеге грантлары быел, Артур Шәйдуллинның «Җаның ни тели» спектаклен кую өчен, Чаллы театрына һәм, «Шүрәле» спектаклен кую өчен, MON театрына бирелә.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Гүзәл ӘДҺӘМОВА, язучы:

«Хәзер мәктәпләрдә бер сәгать татар теле, бер сәгать әдәбият укытылганда, китап укуны, дәфтәр башлап язып баруны таләп итеп тә булмыйдыр. Укытучы ни чарадан бичара фәнгә өстән-өстән кыскача күзәтү ясаса гына. Ә бит баланы иң башта китап укырга күнектерергә, укуны гадәткә әйләндерергә кирәк. Күнегеп китмәсә, ул инде кулына китап алып утырмаячак».

СЫНАМЫШЛАР

31 декабрьдә агачларны бәс сарса, ашлык уңар ● Ел башында җил булса, ел буена җил-давыл тынмас ● Кышын кояш кызарып чыкса, суыта ● Кояш тирәсендә нурлар югары чагылса – буран, түбән чагылса – салкын була ● Колак кычытса, буран булыр.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **8 сәгать 13 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 18 минутта** офык артына күмелачәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 05 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **10 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **6 гыйнварда 7 сәгать 15 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

31 декабрь – актриса, Татарстанның, Россиянең халык артисты Фатыйма Салих кызы Ильскаяның (Хуҗасәетова) тууына 120 ел (1902–1984).

1 гыйнвар – шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Шамил Мәгъйз улы Маннаповның тууына 85 ел (1938–2012);

– актер, Татарстанның, Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Ринат Арифҗан улы Таҗетдиновка 85 яшь (1938);

– язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мансур Хаҗи улы Вәлиевкә 75 яшь (1948);

– музыкант, композитор, Татарстанның халык артисты Фәрит Кәнәфи улы Хатыйповка 75 яшь (1948).

– Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, драматург Илдар Гафур улы Юзеевнең тууына 90 ел (1933–2004).

– актёр Нариман Габдрахман улы Гарифуллинга 70 яшь (1953).

3 гыйнвар – шагыйрь, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мөхәммәт Мирзага (Илфак Мирзамөхәммәт улы Ибраһимов) 70 яшь (1953).

8 гыйнвар – шагыйрь, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фәрит Ибраһим улы Габдрәхимовка 90 яшь (1933).

10 гыйнвар – журналист, язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Госман Гомәр улы Гомәровның тууына 90 ел (1933–2020).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Гыйнварның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 31 декабрь, 3 гыйнвар.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(30 декабрь-7 гыйнвар)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **25 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр** бөер һәм бәвел куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген җөмәдел ахир аеның 7 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Лилия ГАЛИМОВА,
«Татар һәм төрки халыкларның милли конгрессы» оешмасының матбугат үзәге хезмәткәре

МӘГАРИФНЕ ҮЗЕБЕЗ ЯҢАРТЫЙК

Бүген татар милләте өчен ана телен саклап калу – иң төп бурыч. Тел каршында хәвеф – ул ассимиляциянең һәм күпчелек гаиләләрдә татарча сөйләшүне читкә кагу нәтиҗәсе. Туган тел язмышы – татарның үз кулында. Әмма шул ук вакытта укыту-мәгариф системасын тамырыннан башлап яңартырга, үзгәртергә һәм татар, башкорт, якут, бурят файдасына тулысынча яңартырга кирәк. Барча «вак» милләтләр телен юкка чыгара, ә милләтләрнең үзен урыс эченә йотып бетерә торган карагруһчыл мәгариф системасының безгә кирәге юк.

Мәскәүнең Татарстан вәкиллеге каршындагы Иҗтимагый шура җитәкчесе Нәзиф Мириханов фикеренчә, әгәр мәктәпләрдә фәннәрнең бер өлешен татар телендә укыту булмаса, якынча 25 елдан соң татар әдәби теле үләчәк, аның артыннан татар әдәбияте һәм мәдәнияте юкка чыгачак. Татар әдәби телен саклау һәм куллану өчен татар балаларының ким дигәндә 25-30% ы татар телендә өлешчә белем алу мәктәпләрендә укытылырга тиеш. Аның әйтүенчә, Мәскәү татар автономиясенә һәм башка татар оешмаларына Мәскәүдәге бердәнбер 1186 нчы татар мәктәбе белән хезмәттәшлекне саклаарга һәм киләчәктә аны тагын да баетырга, үстерергә кирәк.

«Иң беренче чиратта, мәктәпкә татар балаларын күбрәк җәлеп итү сорала. Мәктәпнең киләчәге буларак аның полилингваль мәктәпкә әверелү мөмкинлеген карарга кирәк. Кызганычка каршы бүгенге шартларда татар милли һәм этномәдәни мәктәпләрен торгызу, көчәйтү турында сүз бара алмый. Милли мәгариф системасы татар телендә (өлешчә яисә кайбер фәннәрдән) белем бирү билингваль, полилингваль мәктәпләрдә яисә шәхси мәктәпләрдә генә алып барыла алачак. Шуңа да иң беренче чиратта, булган мәктәбебезне саклыйк, камилләштерик һәм үзгәртик», – ди Н.Мириханов.

Шул ук вакытта татар мәгариф системасын камилләштерүнең ул тагын бер ысулын тәкъдим итә. Төгәлрәк әйтсәк, кабул ителгән Федераль стандарт (ФГОС) буенча Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе гомумбелем мәктәпләрендә ирекле рәвештә атнага ике сәгать күләмендә татар телен өйрәнү группалары ачу. «Бу эш Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе региональ, бигрәк тә җирле автономияләр тарафыннан ата-аналар белән тирән эш алып баруны таләп итә. Шулай ук, кабул ителгән законнарның практикада үтәлү мөмкинлеген тикшерү дә кирәк. Шунсыз безнең депутатлар законнарга үзгәреш кертү турында тәкъдимнәр белән чыга алмаячак».

Хәзерге вакытта балаларны һәм яшүсмерләрне татар мәдәнияте белән кызыксындыру, аларда ана теленә карата мәхәббәт уяту, туган телне өйрәнергә теләк торгызу һәм гомумән, үз милләте каршында олы җаваплылыкка ия шәхес итеп тәрбияләү өчен безгә дәүләт-мәктәп-милли оешма һәм гаилә бердәмлеген булдырырга кирәк. Чөнки бу чылбыр бары тик бергә эш иткәндә генә, балаларга дөрес аң-белем бирергә, аларны рухлы, зиһенле итеп үстерергә, үз милләтен, халкын, тарихын, гореф-гадәтләрен хөрмәт итүче һәм татар телен башка телләрдән өстен куючы шәхесләр итеп тәрбияләргә мөмкин.

Хәзер икътисади һәм сәяси яктан шактый катлаулы заманда да барлык эшчәнлеген, тормыш мәгънәсен бу якты өметкә баглап яшәүче кешеләр, оешмалар бар. Мәскәүдәге «Татарларның һәм башка төрки халыкларның милли конгрессы» оешмасы нәкъ шундыйлардан. Менә инде 25 ел буена ул татар халкының телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклауга үзеннән зур өлеш кертүче, җәмәгатьчелек эшендә актив кайнаучы оешма булып тора. Оешма җитәкчесе Рөстәм Ямалеев милли мәгариф системасын камилләштерүдә алдынгы нәтиҗәләргә ирешү өчен алты төрле таләп тәкъдим итә.

1. Россиянең татарлар тыгыз яши торган барлык төбәкләрендә, шул исәптән Татарстан Республикасының зур булмаган шәһәрләрендә һәм авылларында М.Шәймиевнең проектына нигезләнгән полилингваль (яисә берничә телне өйрәнүне күздә тоткан) мәктәпләр булдыру.

2. Гомумбелем бирү мәктәпләрендә туган телне өйрәтүче татар группаларын ачу. Мәгариф системасындагы яңа үзгәрешләр буенча, туган телне өйрәнүче группаны оештыру өчен барлыгы 7-8 укучы бала җитә. Бу кагыйдә шул исәптән рус мәктәпләренә дә кагыла.

3. Урта һәм югары белем уку йортларында татар теле һәм әдәбияты укытучыларының әзерлек дәрәҗәсен күтәрү. Моны тормышка ашыру өчен аларны югары сыйфатлы уку әсбаплары, тәҗрибәле укытучылар тарафыннан язылган китаплар белән тәэмин итү.

4. Әгәр чыгышы буенча татар милләтеннән һәм мөселман диненнән булмаган кеше күңеле белән үзен татар дип хис итә икән, ул чыннан да үзен татар кешесе дип танырга хокуклы. Ә инде үзеңне нинди милләткә кертүеңне яшь чагыннан ук билгели башларга кирәк. Бу юнәлештәге эшчәнлекне аеруча әйбәт башкаручы кешеләр бар. Ул балаларга, яшьләргә һәм олыларга аң-белем бирүче, әхлак, намус, туган ил, туган җир, ана кадере, туганлык сыйфатлары, дин, яхшы гамәлләр һәм башка мөһим сорауларны ачыклап бирүче, тирән эчтәлекле вәгазьләр сөйләүче дин әһелләре.

5. Мәгариф системасындагы реформаларны дәвам итеп, нәтиҗәдә Россия Федерациясе күләмендә күпләгән халыклар һәм милләтләрнең үз ана телендә белем алу хокукына ирешү.

6. Шәхси татар мәктәпләрен төзү эшендә эшмәкәрләргә мөрәҗәгать итү. Бирәдә өмет татар байларында, түрәләрендә, татар-мөселман лидерларында. 1917 елгы революциягә кадәрге заманнарда татар мәчетләре белән шәхси татар милли мәктәпләре аерылгысыз бер система булган һәм шул мәктәпләр халкыбызны, татар милләтен һәм телен саклап калган дияргә була. Әлбәттә татар байлары, меценатлары, иганәчеләре ярдәменнән башка шундый зур һәм мөһим эшне башкару күпкә читенрәк булачак.

«Татарларның һәм башка төрки халыкларның милли конгрессы» оешмасының аксакаллары билгеләгәнчә, туган телне саклау һәм аны тиешле дәрәҗәгә күтәрү юнәлешендәге эшне актив позицияле, тырыш һәм уңган кешеләргә тапшырырга вакыт җитте. Әгәр дә ил күләмендә телне өйрәнү буенча 70%тан да кимрәк балалар исәбе чыга икән, ул вакытта андый тел бөтенләй юкка чыгуга дучар! Моңа юл куймау өчен мәгариф системасына ашыгыч рәвештә үзгәрешләр кертергә кирәк. Иң беренче адым – полилингваль мәктәпләр, гомумбелем бирү мәктәпләрендә татар классларын оештыру. Шул чакта гына татар халкының киләчәге якты. Ә балаларыбызга, оныкларыбызга беренче сүзне үз ана телендә әйтү хокукы – нәсел шәҗәрәсе аша тапшырылсын.

Мәскәү.

МӘҖ Җидегән вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

Яңа елга – яңа өметләр белән!

Башкарган эшләргә ел ахырында йомгак ясау – гадәти хәл. Мөселман руханиларының күптән түгел Мәскәүдә үткән халыкара форумында исә, мөһим вакыйга – Идел Болгарында ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган чараларга йомгак ясау белән бергә, хак динебезнең бүгенге хәле вә киләчәгенә, шулай ук яңа дөньяви тәртип һәм глобаль сәясәткә дә кагылышлы проблемалар күтәрелгән. Аларның болай үзара бәйләнештә каралуы аңлашыла да. Чөнки семит диннәренең Урталык җирләренә җәелдерелүе (игътибар итик, ислам дине анда христианлыкка караганда алданрак та кертелә) үзе үк геосәяси ниятле адым булып тора. Икенче яктан, халыкара форумның темасы да «Гаделлек вә уртачалык: дөньяви тәртипнең илаһи принциплары» дип билгеләнгән. Шуңа күрә пленар сессиядә игътибар үзәгендә төп ике төшенчә – гаделлек һәм яңа дөньяви тәртип торган, соңгысы нигезенә уртачалык һәм гаделлек принциплары салынырга, глобаль гаделлек исә Россия һәм мөселман илләренең үзара якынаюына китерергә тиешлеге турында да әйтелгән. Форумда Көнбатыш тарафыннан көчләп тагыла торган дөньяви тәртипнең илаһият кануннары белән каршылыкка керүе, шуңа күрә хәзер инде Көнчыгыш кыйммәтләрен дә исәпкә алган гадел дөньяви тәртип урнаштыру вакыты җитүе турында да сүз булган. Ислам мәзһәбләрен үзара якынайту, Россия мөселманнарының уртак структурасын булдыру кебек колачлырак проблемалар торуы турында да искәртелгән.

Әлбәттә, форумда күтәрелгән мәсьәләләр, тарихи һәм дини яктан да, геосәяси планда да бүген актуаль яңгырый һәм шуңа аларга бу язмада аерым да тукталып үтү урынлы булыр. Ә игътибарны, иң элек, куелган теманың мотлак (абсолют төстә) ачылып бетмәве җәлеп итә. Чөнки гаделлек һәм уртачалык – субъектив төшенчәләр. Аңлаешлы булсын өчен, Украинаны гына алыйк: Мәскәү анда бара торган вакыйгаларны үзенчә бәяли, дөнья җәмәгатьчелеге исә – бөтенләй башкача. Шуңа, форумда куелган теманы да абсолют кыйммәтләр системасында карау лязем. Димәк, сүз анда илаһият кануннарына җавап бирә торган яңа дөньяви тәртип урнаштыру турында барырга тиеш иде. Әлбәттә, төрле илләрдән ислам руханилары җыелган мәҗлестә төп сорауның хәтта тиешенчә куела да алмавы – сәер күренеш. Күрәсең, моның да сәбәбе диннәрнең әлегә сәясәт коралы булып калуы белән аңлатыла. Шуңа күрә, Мәскәүдә узган ул форум да, ихтимал, илдә бүген милли берәмлекләрне бетерү буенча үткәрелә торган мәкерле сәясәтнең (Татарстанның сәяси вә хокукый банкротлыкка чыгарылуын гына алыйк. Хәер, бу инде – үзе аерым бер тема) бер шаукымы, мөселман өммәтендәгеләрнең сәяси идарә ителешен саклап калу ниятендә оештырылган чарадыр. Бу яктан, бериш руханиларның кайда һәм кем канаты астында берләшү темасы тирәсендә кыбырсынулары да шуңа ишарәли.

Дөньяви тәртипнең метасәяси (илаһи яшәешкә кучүне максат иткән) ягын аңлау өчен, Р.Сафин мирасына мөрәҗәгать итик. Ә ул, кешенең рухи үсеше (Аллаһка кайтуы) җәмгыяви тәрбия аша бара, Аллаһ аны яралтылышта бертөрлелекне күптөрлелек итү (инволюция) һәм кабат бертөрлелеккә кайту (эволюция) шәкелендә ниятләгән, дип язып калдырган. Димәк, яңа дөньяви тәртип тә илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүне максат итәргә тиеш була. Ә бу инде илаһи (Аллаһ юлында) берләшүне аңлата. Чөнки ул кануннар бөтен тереклек дөньясы өчен (димәк, барлык диннәр һәм хәтта атеистлар өчен дә) уртак. Илаһи берләшүнең максаты – гармонияле яшәешкә ирешү. Ул чакта инде, мәзһәбләрнең генә түгел, диннәрнең үзара якынаюы да илаһи нигездә хәл ителәчәк. Ә бәгъзеләрнең, ничек һәм кем канаты астында берләшергә, дип йөдәве, асылда, геосәяси (иблиси) нигездәме, әллә метасәяси югарылыктамы, дигән дилеммага кайтып кала. Россия мөэминнәре өчен инде ул, «кириенколар» тирәсендә берләшикме, әллә Аллаһ юлындамы, дигән икеләнүне аңлата. Кызганычка, күпләр әлегә беренче вариант тирәсендә кайнаша.

Ислам яңарышына килгәндә, ул тарихи вә дини яктан да, метасәяси планда да бары Болгардан һәм Урталык җирләреннән генә башлана ала. Татарда бүген инде үзенә йөкләнгән илаһи миссияне (илаһи яшәештә үрнәк һәм әйдәп баручы көч булу) аңлау сизелерлек ныгый. Ә Татарстан җирендә рухи яңарышка әзерлек хәтта символлар дәрәҗәсендә дә бар (бу хакта газетабызда тәфсилле сүз күптән булды, МҖ №32, 04.09.2015). Лидерлыкка килгәндә, Аллаһ юлында рәсүли аң югарылыгына кемнәр ирешә – рухи яңарышны да шулар җитәкләр. Алла теләсә, югары әзерлекле руханилар алга таба татарда да үсеп җитәр, дигән өметтә калыйк!

Фоат УРАЗАЙ.

Ассамблеягә дәрәҗәле статус

Татарстан халыклары ассамблеясенә Берләшкән Милләтләр Оешмасының Икътисади һәм социаль советы каршында консультатив статус бирелде. Бөтендөнья оешмасы белгечләре дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, яшьләр оешмалары белән хезмәттәшлек өлкәсендә Ассамблея туплаган тәҗрибәгә БМО мәйданчыгында ихтыяҗ булуын билгеләп үтте.

Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Халыклары ассамблеясе Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, халыкара оешмада консультатив статус алу дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, шулай ук Россия Федерациясе халыкларының традицион кыйммәтләрен үстерү буенча Россия төбәкләре тәҗрибәсен алмашу өчен мөмкинлек бирә. «Безнең республика һәм ил өчен, гомумән, чит илләрдәге коллегалар белән хезмәттәшлек итү өчен яңа мәйданчык ачылды, – дип басым ясады парламент җитәкчесе, – безне ишетсеннәр өчен барысын да эшләргә тырышачакбыз».

Консультатив статус – иҗтимагый оешмалар һәм БМО арасындагы мөнәсәбәтләрнең рәсми раслануын белдерә, ул БМО эшендә катнашырга мөмкинлек бирә. БМОның Икътисади һәм социаль советы каршында аккредитацияләнгән иҗтимагый оешмалар рәсми утырышларда катнаша, язма һәм телдән гаризалар белән чыгыш ясый, Хөкүмәтләрнең рәсми делегацияләре, БМОның вазыйфаи затлары һәм башка иҗтимагый оешмалар вәкилләре белән очрашуларда, дискуссияләрдә, интерактив диалогларда һәм БМО мәйданчыгында фикер алышуларда катнаша ала.

Пьесалар бәйгесенә нәтиҗәләр

Камал театрында «Яңа татар пьесасы-2022» бәйгесенә йомгак ясалды. Комиссия I премиягә ике әсәрне лаек дип тапкан: «Картлар күңеле кемнәрдә?» әсәре белән Уфадан Әлфис Гаязов (Илтифатлы) һәм рус телендә язылган «Последние люди» пьесасы белән кинорежиссер һәм драматург Салават Юзеев (Аббас Бахытов).

II һәм III премия Әлмәттә яшәүче Мамадыш егете Артур Ибраһимовка тапшырылды. Аның Зөлфәт Нургалиевич псевдонимы белән бирелгән «Бабайның бабасы» һәм Мәҗүсиев Мөхәммәт Гайсиевич псевдонимы белән бирелгән «Күрше авыл догалары» пьесалары комиссиядә кызыксыну тудырган.

«Милли классиканы заманчалаштыру өчен» махсус номинация – Раушан Шәриповка (Абдул) «Ач күзеңне, килен бу...» әсәре өчен бирелде. Кызыксындыру премиясенә «Бездә туй – аерылышабыз!» комедиясе өчен Мансур Гыйләҗев (Тамада), «Пароль – Юк!» әсәре өчен Айгөл Әхмәтгалиева (Фәттах) лаек дип табылган.

Татарстан Мәдәният министрлыгының махсус премиясен министр урынбасары Дамир Натфуллин Рөстәм Галиуллинга (Профессор түгел) «Көзге кайтаваз» пьесасы өчен тапшырды.

Шәриф Камалны яд итү

Моннан 80 ел элек 22 декабрь иртәсендә татар әдәбияты классигы, язучы, драматург һәм журналист, татар әдәбиятында новелла жанрына нигез салучыларның берсе булган Шәриф Камалның (Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев) йөрәге тибүдән туктый. Ул вакытта Бауман урамындагы Матбугат йортына урнашкан Тукай клубында җеназа мәрасиме үткәрелә. Бөек Ватан сугышы барган авыр вакыт булса да, ераккан язучысын соңгы юлга озатырга гаять күп кеше җыелуы теркәлеп калган. Әдипне Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында җирлиләр.

Вафат булган кәнендә язучыны искә алып, Татар әдәбияты тарихы һәм Шәриф Камалның мемориаль фатиры музее директоры Айдар Шәйхин оештыруында бер төркем музейчылар, «Мәрҗани» мәчете имамы Рамил хәзрәт Миңгәрәев, Кариев театры директоры, шагыйрә Луиза Янсуар, язучының бертуганының оныклары Нәфис Байгилдиев һәм Айрат Байгилдиев каберен зиярәт кылды. Рамил хәзрәтнең Коръән аятьләре укып дога кылуыннан соң кабергә кызыл канәфер чәчәкләре куелды.

Шәриф ага замандашлары хәтеренә чын зыялы шәхес булып кереп калган. Шагыйрә Луиза Янсуар язучының бергә аралашып яшәгән замандашларының үз истәлекләрендә аны бик тыныч, сабыр кеше дип теркәп калдыруларын искә төшерде. «Ул үз тирәсенә кешеләрне дә туплый алган, аларга күңел җылысын да биргән, өенә килгән дуслары – сәнгать һәм әдәбият әһелләрен дә һәрвакыт якты йөз белән каршылап, гамьле әңгәмәләр корырга да мөмкинлек тудырган. Шул ук вакытта үзеннән соңгыларга аталарча, агайларча васыять итеп иҗади сүзен дә, фатихасын да биреп калдыра алган», – диде Л.Янсуар.

Әмма шул ук вакытта Шәриф Камалның кабер ташы бик мөселманча түгеллегенә, үзенчәлекле булуына игътибар итми мөмкин түгел иде. Аның формасы православ чиркәве гөмбәзен хәтерләтә. Язучының абыйсы Гыймадинең оныгы Нәфис Байгилдиев искәртеп үткәнчә, мөселманнарны вафат булган көнендә үк җирләү гадәте бар. Аннары Бөек Ватан сугыш барган чорда – илебез өчен авыр вакытларда кыска гына вакытта граниттан кабер ташы эшләтеп алу мөмкин булмый. Шуңа да христианнарча әзерләп куелган ташны алалар. Инде 80 ел үтүгә карамастан, ул һаман да Шәриф аганың кабердә тора. Нәфис Байгилдиев, ташны алыштыруларын сорап, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка да хат юллаган. «Ташны Шәриф абыебызның тууына 140 еллык юбилеена, ягъни 2024 елга алыштырырлар, дип ышанам», – диде ул.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

БЕРГӘ БУЛЫЙК!

*«Мәдәни җомга»га 2023 елның I яртыеллыгына гыйнвар каникуллары вакытында да язылып була. **«Мәдәни җомга»** газетасына Татарстанда язылу индексы – **П2355.***

1 нче биттә - Казанның Кремль урамы.
Фото: president.tatarstan.ru.

«Ярдәм» уңышлары

Узып барган ел «Ярдәм» хәйрия фондының тернәкләндерү үзәге өчен уңышлы елларның берсе булган. Алар турында «Ярдәм» Гомуммилли хәйрия фонды советы рәисе, Татарстан мөфтиенең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе Илдар Баязитов журналистларга ел нәтиҗәләренә багышланган матбугат очрашуында сөйләде.

Иң әһәмиятле һәм күңелле яңалык – «Ярдәм» мәчете биләмәсендә «ДАН» күпфункцияле спорт комплексы ачылу. Биредә физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә, шул исәптән коляскадагы инвалидларга да спорт белән шөгыльләнү өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган. Күнегүләр өчен заманча җиһазланган тренажер залларында һәркемгә, үз авыруына карап, махсус дәвалау физкультурасы тәкъдим ителә. Шул ук вакытта биредә паралимпия җыелма командасы өчен спортчылар да әзерләнә. Коляскалы инвалидлар һәм сәламәт кешеләр «ДАН» комплексының күп функцияле уен кырында исә триатлон, теннис һәм баскетбол, волейбол, футбол, гандбол буенча шөгыльләнә. Биредә шулай ук бочча уены буенча республика күләмендә сборлар да үткән. Комплекста фитнес-кабинетлар, уен залларыннан тыш массаж кабинетлары, юыну бүлмәләре, сауна җиһазланган. Шунда ук сәламәт кешеләр өчен аерым фитнес зал булдырылган. Инвалидлар комплекста бушлай шөгыльләнә.

Казанның Левченко бистәсендә «Сөләйман» мәчете төзелеше дә алып барылган. Бинага гөмбәз урнаштыру тантанасы быел сентябрь аенда үткәнен хәтерлибез. Мәчеткә тәрәзәләр дә куеп өлгергәннәр. Хәзерге вакытта эчке эшләр бара. «Сөләйман» мәчете 2023 елда файдалануга тапшырылыр дип уйланыла. Мәчеттә малайлар өчен пансионат урнаштыру планлаштырыла. Алга таба «Сөләйман»да коляскалы инвалидлар өчен тернәкләндерү үзәге ачарга да ниятлиләр.

Күптән түгел «Ярдәм»дә якыннары мобилизацияләнгән кешеләр өчен «Батырлык-Мужество» акциясен башлап җибәргәннәр. Хәзерге вакытта 700 гә якын гаиләгә азык-төлек җыелмасы, 178 мең сумлык дарулар, 453 меңлек кием-салым бирелгән.

«Ярдәм» мәчете биләмәсендә социаль ашханә төзелеп килә. Әлегә кадәр мохтаҗларга кайнар аш урамда таратылган булса, тиздән аларга җылы бинада ризыклану мөмкинлеге тудырылачак. «Ярдәм» хәйрия фонды алып бара торган «Тормыш юлы» акциясе дә дәвам итә. Аның кысаларында 350 кешенең атнага биш тапкыр кайнар төшке аш белән туклануы оештырыла. Бер ел эчендә мохтаҗларга, инвалидларга, йорт-җирләре булмаганнарга 84 000 ланч-бокс таратылган. Рамазан аенда һәр көнне 1500 кеше өчен ифтарлар әзерләнгән. Моннан тыш «Минем ярдәм» дигән социаль акция кысаларында 1500 мохтаҗ гаиләгә азык-төлек җыелмасы тапшырылган. Болардан кала фонд хезмәткәрләре Казан шәһәре инвалидлар оешмаларына өч тонна бәрәңге, 7,5 тонна корбан ите өләшкән.

«Күңел күзе белән укыйм Коръән» акциясе ярдәмендә Луи Брайль шрифты белән басылган Коръән дә таратылган. Бу уңайдан «Ярдәм» хәйрия фондының 2022 елдагы тагын бер зур яңалыгы – «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» китабын Луи Брайль системасы буенча бастыра башлавы. Тугыз томнан торган тәфсир фондның белгечләре тарафыннан ел ярым дәвамында әзерләнгән. Шул ук вакытта «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә»нең БДБ илләрендә беренче тәҗрибә булуын әйтергә кирәктер. Журналистлар белән очрашуда «Ярдәм» фонды президенты Илһам Исмәгыйлев, фондның вице-президенты, тернәкләндерү үзәге директоры, Казан шәһәре Думасы депутаты Мәликә Гыйльметдинова, «Ярдәм» фондының белгече Фәнис Мингәрәев һәм башкалар катнашты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

Татарстанны рәис җитәкләячәк

Татарстан депутатлары республика җитәкчесенең яңа атамасын хуплаган карарны кабул итте. Татарстан Конституциясенә республиканың югары вазыйфаи заты атамасын үзгәртүне күздә тоткан төзәтмәләр белән закон проекты кабул ителде. Иң югары вазыйфаи зат «Татарстан Республикасы Рәисе» дип аталачак.

Дәүләт Корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе Альберт Хәбибуллин сүзләренчә, рус телендә бу атама «Глава – Раис Республики Татарстан» дип гамәлгә кертеләчәк, ә кыскартылган варианты нигезендә, «Раис Республики Татарстан» дип кенә дә атарга мөмкин булачак.

Закон проекты парламент президиумы тарафыннан кертелгән. Бер көн әүвәл комитет утырышында депутатлар тәкъдим ителгән вариант белән килешмәде. Федераль Закон нигезендә, «Глава» яки «Башлык» дип кенә түгел, башкача атау мөмкинлеге дә искәртелде.

«Татарстан Республикасы Рәисе» атамасы тарихи, милли, мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алырга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта, Рөстәм Нургали улы Миңнеханов Президент буларак сайланды. Гражданнар аңа президентка кандидат буларак тавыш бирде. Моңа бәйле рәвештә, яңа атама бары тик яңа сайланган югары вазыйфаи затка гына кулланылачак», – диде Альберт Хәбибуллин. Республиканың иң югары вазыйфаи затын сайлау 2025 елның көзендә узачак.

«Рәис» атамасын Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та хуплады. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «компромисс вариант кабул ителде» дип белдерде. Закон проекты өчен 78 депутат тавыш бирде, өч кеше каршы булды.

Мөслимлеләр беренче!

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрында Гран-при алган Мөслим районының халык театры коллективы «Зәңгәр шәл» спектаклен тәкъдим итте.

Төп бүләкне Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров тапшырды.

– «Идел-йорт» театр коллективлары бәйгесе тулы бер хәрәкәткә әйләнде. Ул үз актуальлеген югалтмыйча егерме икенче тапкыр үткәрелеп килә, илебезнең татар халык театрларын берләштерә, – дип ассызыклады ул.

Быел конкурста йөз театр коллективыннан ике меңнән артык кеше катнашты. «Идел-йорт – 2022» театр коллективлары бәйгесенең финалистлары үз спектакльләрен В.И.Ленин мәдәният сараенда 4800 дән артык тамашачыга күрсәтте.

«Урман күле» яшьләрне туплый

«Урман күле» исемле яшьләр форумы әкренләп матур традициягә әверелә бара. Менә инде берничә ел дәвамында Мәскәү шәһәре һәм өлкәсенең татар яшьләрен бергә җыеп, аларның тормышын тагын да ямьләндерә: яңа танышлар, кызыклы ачышлар һәм кирәкле белемнәр белән баерга мөмкинлек бирә.

Бу юлы «Урман күле» төбәкара яшьләр форумы Мәскәү өлкәсенең Дубна шәһәрендә «Ратмино» исемендәге ял йортында үтте. Җыен өлкәнең мәгълүмати һәм социаль коммуникация министрлыгы тарафыннан бирелгән грант ярдәмендә, Төбәкара татар милли-мәдәни автономиясе белән Дубна шәһәре хакимияте берлегендә оештырылды. Шулай да җыенның программасын төзү һәм аны тормышка ашыру Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Мәскәү өлкәсенең Төбәкара милли-мәдәни автономиясе рәисе Фәрит Мөхтәсәров һәм Мәскәүдәге «Татарларның һәм башка төрки халыкларның милли конгрессы» оешмасы җитәкчесе Рөстәм Ямалеев, әлеге оешмада яшьләр белән эшләрне алып баручы Гөлнара Яруллина башлап йөрде.

Бөтендөнья татарлар конгрессының яшьләр бүлеге җитәкчесе урынбасары Ләйсән Фәхриева үз чыгышында яшьләр өчен махсус проектлар белән таныштырып үтте. Алар арасында – 2006 елдан бирле дәвам иткән, күбебезгә таныш «Мин татарча сөйләшәм» дигән яшьләр программасы. Бу проект нигезендә татар телендә сөйләшүне шәһәр урамнарында популярлаштыру максаты ята. Һәм бу проектның тагын бер әһәмияте – ул Казан белән генә чикләнми, Чаллы, Омск, Төмән, Иваново, Чиләбе, Ижау шәһәрләрендә үткәрелә һәм үз эченә 10 000 нән артык кешене колачлый. Бөтендөнья татарлар конгрессының яшьләр бүлеге карамагында тагын берничә кызыклы проект бар. Шундыйлардан: заманча татар мәдәниятенең халыкара фестивале «Tat cult fest», «Татар дозор» исемле квест уены, «Печән базары» фестивале, «Татар кызы» халыкара конкурсы, «Татарча диктант» проекты. Соңгысы «Урман күле»ндә катнашучылар өчен дә үткәрелде.

Форумда «Росмолодёжь» оешмасының эшмәкәрлек өлкәсе җитәкчесе Марат Мотыйгуллин да чыгыш ясады. Ул хәзерге буын вәкилләре өчен, аеруча актив һәм булдыклы яшьләр өчен эшмәкәрлектә уңышка ирешү ысулларын сөйләп үтте. Казан кунагы, эшмәкәрлек тренеры Диана Валиуллина яшьләргә матур һәм уңышлы чыгыш ясау серләрен ачты.

Дубна шәһәре хакимиятенең яшьләр бүлеге җитәкчесе Михаил Богомолов калада яшьләр өчен үткәрелә торган проектлар турында фильм-презентация тәкъдим итте.

Форум кысаларында Мәскәү өлкәләреннән килгән татар оешмалары җитәкчеләре Дубна шәһәренең милли-мәдәни үзәгенә барып, андагы эшчәнлек белән таныштылар, автобус экскурсиясе, кызыклы музыкаль уеннар, татарча җыр-биюләр, тематик яктан файдалы мастер-класслар үткәрелде.

Лилия ГАЛИМОВА.

●2022 елның "иң көчле" паспорты аталган. Аның белән дөньяның 121 иленә визасыз барып була. Бу – Берләшкән Гарәп Әмирлекләре паспорты. Россия паспорты исемлектә 38 нче урынга куелган, аның белән 78 илгә визасыз кереп була, 45 илдә, барып җиткәч, виза ясатырга мөмкин. Исемлектә иң соңгы урында – Әфганстан паспорты, аның белән нибары 5 илгә барырга була.

●Татарстанда 2023-2025 елларда ихтыяҗ зур булачак һөнәрләр исемлеге расланган, анда барлыгы 130 һөнәр һәм белгечлек кертелгән. Алар арасында архитектура, төзелеш, нефть һәм газ скважиналарын бораулау, аддитив технологияләр (3D-принтер ярдәмендә өчүлчәмле объектлар бастыру), мехатроника һәм мобиль робототехника, эретеп-ябыштыру, автомобильләр ремонтлау, суднолар төзү һәм суднолар йөртү, фармация, үсемлекчелек, зоотехния, мәгариф, зәркәнчелек эше, дизайн, туризм һәм башкалар бар.

МИРАСЫБЫЗ сувенир булып калмаска тиеш

2022 елның санаулы сәгатьләре калып бара. Президент В.Путин аны Россия халыкларының мәдәни мирас елы дип игълан иткән иде. Ел дәвамында байтак чаралар үтте. Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган «Хәзерге заманда традицион мәдәниятне саклау һәм үстерү тәҗрибәсе» исемле халыкара конференция шундый чараларның берсе булды. Мирасны саклау өчен күп эшләр башкарылса да, чынлыкта, без юлның башында гына әле. Татарстан, Дагстан, Ингушетия, Азәрбайҗан, Грузия, Казахстан, Үзбәкстаннан сәнгать белгечләре катнашында узган бу җитди сөйләшүдә моңа тагын бер кат инандык.

Шау-шуга әйләнгән йола-бәйрәмнәр

Җәй айларында Сабан туйларны гөрләтеп уздырабыз, елга бер «Каравон» рус фольклор фестивалендә җырлыйбыз-биибез дә, аннары елы буе мәдәни мирасны саклауда эшләп хәлдән тайган сыман канәгать йөри бирәбез, ягъни мирасны һәрдаим түгел, елга берничә мәртәбә, бәйрәмнәрдә, форсат чыкканда гына исебезгә төшерәбез. Кулланмыйча торсаң, эш кораллары тутыккан, яраксызга чыккан кебек, милли йолаларыбызның да чын асылы, ерак гасырларга барып тоташкан тирән мәгънәсе югала бара. Сабан туйлары халыклар дуслыгы бәйрәменә әверелде, мәйданда җыелышып кыздырылган дуңгыз ите белән сыйлану, сыра чөмерү гадәти күренешкә әйләнде. Үзгәртеп кору елларыннан башлап мәдәни мирасны саклау әнә шундый колачлы, әмма вакытлыча төс алуы хакында сәнгать фәннәре докторы, Мәскәүдәге С.Г.Строганов исемендәге сәнгать-сәнәгать дәүләт академиясенең профессоры Ралия Мусина бик ачынып сөйләде. Бүген бер-беребезне уздырып милли сувенирлар ясыйбыз. Элек исә йорттагы һәр нәрсә матурлык өчен түгел, эштә файдаланылган. Кашага, чаршау, ашъяулык, палас, урын япмаларын эш юкта эш булсын өчен түгел, кирәккә күрә чиккән-тukкәннәр. Көн саен кулланылышта булгач, аларның бизәкләре һәм мәгънәләре канга сеңгән. Мәдәни мирасыбызның кулланылыштан төшеп калып, сувенирга әйләнүе аның яшәү гомерен озынайтмый, кыскарта гына.

Мирасны саклау кануннан башлана. 1999 елда «Халык һөнәрчелеге турында» кабул ителгән канунда һөнәрчелекнең рухи кыйммәтенә басым ясалган булса, әлеге канунга кертелгән төзәтмәләр халык һөнәрләрен табыш алу өчен чыганакка әйләндерә. Галимә бу хакта ризасызлыгы белән дә уртаклашты.

Татарстанда тукучылык

Сәнгать фәннәре докторы, Г.Ибраһимов исемендәге институтның Сәнгать белеме үзәге җитәкчесе Рауза Солтанованың сүзләреннән аңлашылганча, республикабызда туку эше алга китсен өчен, төрле чаралар күрелә. Мәдәният министрлыгы каршындагы Ресурс үзәге дә бик тырыша. Институт та бу мәсьәләгә бик игътибарлы. Сәнгать фәннәре докторы Ф.Вәлиевнен 100 еллыгына багышлап оештырылган тукучылык буенча халыкара симпозиум үзе генә дә ни тора! Һәрдаим экспедицияләргә чыгалар, туку сәнгатенең бай тарихына шаккатып кайталар. Актаныш районының Күҗәкә авылыннан Г.Нуруллина, мәсәлән, Мәскәүгә җитәр иде суккан палаcларын, дия торган булган. Минзәлә районыннан оста куллы хатыннарның эшләнмәләре 1980 елда Мәскәүдә ВДНХда күрсәтелгән. Әмма барыбер язылар арасында тукучылар бик сирәк. Моның бер сәбәбе – Казан сәнгать училищесы, мәдәният һәм сәнгать институты, Лениногорск музыкаль-художество педагогика көллиятендә, Лениногорскидагы М.Хәйретдинов исемендәге сәнгать мәктәбендә бу һөнәр өйрәтелсә дә, һәм Казанның А.В.Козин исемендәге 7нче гимназиясендә Л.П.Кочнева җитәкчелегендә тукучылык музее оештырылуга, Балтач районының Субаш урта мәктәбендә технология укытучысы Л.Ә.Фаязовның балалар белән туку һөнәрен яңартырга омтылуына карамастан, республикабызда бу һөнәр буенча бер тәртипкә, җепкә салынган укыту эшенең булмавы. Шуңа күрә Алексеевский туку фабрикасында нибары җиде тукучы эшли. Иң яшенә – 40, иң өлкәненә 57 яшь. Мең яшәр Казаныбызның үзәгендә фабриканың махсус кибете дә булмагач, тукучылык эшенә яшьләрдән кем әйләнеп карасын? Тырышканда исә туку һөнәребезне каюлы күн сыман республикабызның брендына әйләндерергә мөмкин. Аның өчен балаларыбызны яшьтән үк тукырга өйрәтергә, институтларда теорияне практика белән бергә алып барырга, станоклар белән тәэмин итәргә, осталарны салымнардан азат итәргә, ары китеп, халыкара кибетләр булдырырга һ.б. чаралар күрергә кирәк. Шунысы сөенечле, Сәнгать белеме үзәге оештырган сәяхәттән соң, Кырымда Мамут Чурлудан тукырга өйрәнеп кайткан осталарыбыз Актаныш, Буа, Казан, Чаллыда сәнгать мәктәпләрендә балалар белән осталыкларын уртаклаша.

Рус костюмының бәхетле язмышы

Тарих фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) Федераль университеты доценты, рус костюмын торгызуга күп көч куйган Елена Гущинаның чыгышыннан соң, татар милли костюмы кайчан бәхеткә тиенер, дигән сорау туды. Белгечләр әле һаман да хаситәне камзулның эченнән кигәннәрме, әллә тышыннанмы, дигән мәсьәләдә бер уртак фикергә килә алмый. Рус костюмының исә язмышы бәхетлерәк күренә. 2021 елда Пушкин исемендәге мәдәният үзәгендә зурлап узган күргәзмәдән соң, калын каталог нәшер ителгән. Татарстан музейларындагы рус костюмын өйрәнеп берсе – сарафаннарга, икенчесе баш киемнәренә багышланган тагын ике том китап бастырып чыгарганнар. Рус халкының гамәли бизәү сәнгатенә багышланган ике китап һәм XIX гасыр ахыры – XX йөз башы рус халык костюмы турында бишенче том чират көтә. Бүген исә Татарстан Халыклар дуслыгы йорты белгечләренең соравы буенча Идел буе халыкларының костюм репликалары эшләнелә. Бу эшкә күрше республикалар да җәлеп ителгән. Республика халкын милләтләргә бүлмичә фикер йөрткәндә исә, костюм мәсьәләсендә проблемалар байтак икән. Милли костюм тегүче-чигүчеләргә методик материаллар җитенкерәми. Белемсезлектән әллә нинди көлкеле хәлләргә калучылар бар. Бигрәк тә авыл, районнардагы мәктәп музейларында аяныч хәлләр күп очрый. Шәлне эскәтер итеп өстәлгә ябып куярга да күп сорамыйлар. Хатын-кыз манекенына ир-ат күлмәген кидертү очракларына да юлыккан бар. Фондларына кереп карасаң исә, әллә нинди сирәк экспонатлар очратырга мөмкин. Музей җитәкчеләре кайчак нинди байлыкка ия булганын үзләре дә белми, – дип аптырап сөйләде Елена Гущина. Фольклор коллективларының аякларына чабата өстерәп, ялтыйолт килеп торган тукымалардан зәвыксыз тегелгән күлмәкләр киеп сәхнәгә чыгулары да наданлыгыбыздан килә. Республикадагы бөтен музейларга баш Милли музеебыз бар лабаса! Нигә ул районнардагы кечкенә музейларга методик ярдәм күрсәтми, ник хезмәткәрләр белән белем-агарту семинарлары уздырмый? Фольклор коллективлар өчен костюм тегү мәсьәләсен ник берәү дә игътибарга алмый? Кызганыч ки, бу сорауларга әлегә җавап юк.

Игътибарга мохтаҗ мәктәп музейлары

Мәктәп музейлары темасын дәвам итеп, сәнгать фәннәре кандидаты, Г.Ибраһимов институтының өлкән фәнни хезмәткәре Людмила Шкляева Самара, Оренбург, Чиләбе районнарына барулары турында бәян итте. Галимәнең әйтүенә караганда, бериш мәктәп музейларында бик сирәк экспонатлар очрый. Мәсәлән, Чиләбе өлкәсенең Уй районы Әмин авылының мәктәп музеенда табаны сарык тиресеннән булган чүпрәк аяк киеме табылган. Урал ягы хатын-кыз костюмының бер өлеше саналган бу экспонат байтак тикшерүчеләрнең хезмәтләрендә телгә алынса да, шушы мәктәп музееннан башка аның бүтән беркайда һәм беркемгә күзенә чалынганы булмаган, ди. Шундый сирәк экспонатларга ия булса да, мәктәп музейларының игътибардан читтә калуы борчый. Галимә музей коллекциясен туплаучыларга хезмәт хакы каралмавы җәһәтеннән борчылуын белдерде. Музей экспозициясе төзүчеләрнең махсус белемнәре булмавын кайбер әйберләргә инвентарь номерлар сугылмавыннан ук күренә, исәп кенәгәләре юк. Теркәлеп бармагач, иҗат әсәрләренең авторлары, тапшыручыларның исемнәре, тапшырылган елы онытыла. Еш кына экспонатларны саклау шартлары бозыла. Татар мәктәпләрен ябу модага, милләтебез өчен исә афәткә әйләнде. Мәктәп ябылгач, музей нишли? Экспонатлары төрле җирдә таралып ятамы? Мәктәп музее булса да, бәһасез мәгълүмат чыганагы бит алар!

Француз яулык мәсьәләсе

Сәнгать фәннәре кандидаты, Г.Ибраһимов институтының фәнни хезмәткәре Ольга Улемнова Үзбәкстанда борынгыдан килгән басма бизәкле тукыма (үзбәкчә читлик) сәнгатен өйрәнгән. 1997 елда Үзбәкстан Президенты И.Кәримовның «Халык һөнәрчелеге һәм гамәли бизәү сәнгатенә ярдәм чаралары турында» карар кабул итеп, бөтен һөнәрчеләрне салымнардан һәм таможня түләүләреннән азат итүе, күпләп һөнәрчелек үзәкләре, остаханәләр ачылуы онытыла язган яки сүлпәнәйгән милли һөнәрләргә, шул исәптән басма бизәкле тукыма сәнгатенә яңа сулыш өрүе турында сөйләде. ЮНЕСКО чараларының берсе буларак ООН үсеш программасы ярдәме белән Сәмәркандта тукымага бизәк басу осталарының Үзбәкстанның төрле төбәкләреннән егермеләп кеше белән осталык серләре уртаклашуы бу һөнәрне аеруча җанландырырга ярдәм иткән. Анда катнашкан Мәликә Хәбибова үзе тукымага бизәк басу остасына әверелгән, гаилә остаханәсен ачкан, улы Дамирны калыплар кисәргә өйрәткән һәм Бохара университетында басма бизәк сәнгатен укытуны җайга салган. О.Улемнованы тыңлаганда бер сорау тынгылык бирмәде, татарларны Урта Азия белән элек-электән мәдәни, сәүдә, тарихи җепләр бәйләгән. Милләттәшләребезнең, бигрәк тә XIX-XX гасыр чигендә борынгы һөнәрләрне торгызып, кәсеп итүдә зур нәтиҗәләргә ирешкәне, бай сәүдәгәрләргә әверелгәне, сәүдәдән килгән акчаны мәдрәсә ачуга, ярлыларга ярдәмгә сарыф иткәннәре билгеле. Шуңа өстәп, татарда «басма», «калып» сүзләре киң кулланыла. Шулай икән, басма бизәкле тукымалар бездә дә булуы ихтимал ич. Туташ-ханымнарыбызның күңелен яулаган француз яулык – шул басма бизәкле тукыманың нәкъ үзе бит инде. Бу мәсьәлә тирәнтен өйрәнүне көтә, димәк.

Курчаклы уены

Сәнгать фәннәре кандидаты, Г.Ибраһимов институтының фәнни хезмәткәре Наталья Герасимова Үзбәкстанда курчаклар уенын өйрәнсә дә, уйнап йөрмәгән – Хивада курчак ясаучы Матякуб Матякубов, Бохарадан Рано Эшанкулова, шулай ук Бохарада яшәүче милләттәшебез Искәндәр Хәкимовтан курчак ясау серләренә төшенгән. Рано ханымның курчак белән мавыгуы һөнәри эшчәнлеге белән бәйле, ул – Бохара музее хезмәткәре, сәнгать белгече. Зур хыялы курчак музее булдыру. Матякуб һәм Искәндәрнең курчаклары исә курчак театрыннан «чыккан», ягъни алар курчак театрындагы спектакль геройлары үрнәгендә иҗат итә башлый һәм һәркайсы үз стилен булдыра, зур уңышка ирешә.

(**Дәвамы 6 нчы биттә**).

Мирасыбыз сувенир булып калмаска тиеш

(Ахыры. Башы 5 нче биттә).

Искәндәрне курчак сувенирларның атасы дип йөртәләр. Бу һөнәр белән ул егерме елдан артык шөгыльләнә. Курчаклар тарихы – Үзбәкстан сәнгатенең борынгы катламнарына барып тоташа. Француз яулык кебек, татарда курчак мәсьәләсе дә күңелне җилкендереп куйды. Милли курчакларыбыз булмаса, бүген Актүбә уенчыгы һәм башка курчак, уенчык ясаучылар шулкадәр ишәймәс иде. Татарда да курчаклар борынгы чорларда ук булган, дип уйларга нигез бар.

XXI гасырда мәдәни мирас презентациясе

Ш.Мәрҗани институтының фәнни хезмәткәре Динә Гатина-Шәфыйкова XXI гасырда мәдәни мирас турында сөйләгәндә «Милли хаситә» кебек реконструкциягә йөз тоткан берләшмәләрнең азлыгына уфтанды. Реконструкция тәкъдим итәрдәй фестивальләр белән дә мактана алмыйбыз, «Республикабызда «Культурный код» фестивале ике тапкыр үтте үтүен, быел майда Кремльдә милли костюм театры да ачылды. Әмма икесенең дә концепциясе эшләнеп бетмәгәч, күңелдә байтак сораулар калды. Реконструкциягә, әллә этнодизайнга йөз тотабызмы без әлеге чараларда? Гомуммилли катламга килгәндә, галимә фольклор ансамбльләрне, хәтта җыр һәм бию дәүләт ансамбле костюмнарының үрнәк-өлге түгеллеген ассызыклады. Аның каруы филармония җырчылары оештырган, татар, рус, мари, чуаш, удмурт, мордва, башкорт сәнгатенә йөз тоткан «ZAKARIA» фольклор төркеме кызыксыну уята, диде. «BURO BANU» ательесы шулай ук күпләрнең күңелен яулаган. Тагын бер юнәлеш – йола-бәйрәмнәргә бәйле һөнәрләр. Бу өлкәдә төрледән-төрле авторлар эшчәнлек алып бара. Интернет челтәрләрендә шәхси акаунтлары аларга популярлыкларга ярдәм итә. Кибетләрдә дә чигелгән сөлгеләр, түбәтәйләрне еш очратырга мөмкин. Әмма җитди реконструкция ясаучыларның аз булуы милли һөнәрләребезнең асыл мәгънәсе югалуга китерә. Шул ук вакытта яңа мәгънәләр барлыкка килү сөендерә. Яңа буыннар милли кием аша мәдәниятебезгә мөнәсәбәтен белдерә.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Туган тел, Сабан туе һәм миллилек…

Узган атнада Татарстан Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев конгресснең узган елгы эшчәнлеген яктыртуда катнашкан журналистлар белән очрашты. Сөйләшүгә төбәкләрдә һәм чит илләрдә эшләүче милли матбугатыбыз журналистлары да онлайн форматта кушылды.

В.Шәйхразыев очрашуны Идел Болгарстанында ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгы кысаларында үткәрелгән тантаналар, федераль, авыл, шахтерлар Сабан туйлары, Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллыгы, VIII корылтай, 1,1 миллион кеше катнашында үткән «Татарча диктант» акциясен, Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенын, «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре», «Татар журналистлары», «Милли тормыш һәм дин» Бөтенроссия форумнарын, һәм ел дәвамында булган башка вакыйгаларны искә алудан башлады.

Очрашуда күтәрелгән төп мәсьәләрнең берсе – туган телебез. Россиянең милләттәшләребез укмашып яши торган күп төбәкләрендә – Башкортстан яисә Төмәнме, Чиләбе йә Мәскәүме – татар мәктәпләре, татар класслары бар. Әлбәттә, алар артуга юнәлеш тотмый. Конгресс бүген булганнарын саклап калуны максат итеп, I-IX класслар өчен дәреслекләр алып, Россия төбәкләрендәге татар мәктәпләренә һәм классларына туган телебездәге әсбапларны тарата. «Мәгариф һәм фән министрлыгы да, татар теле һәм әдәбияты укытучыларын җыеп, яки урыннарга барып утырышлар, сөйләшүләр үткәреп тора. Министрлык, урыннардагы мәктәпләр белән һәрвакытта да бергәләп эшлибез. Безнең сафка автономия җитәкчеләре дә кушыла», – ди В.Шәйхразыев.

Бөтендөнья татар конгрессына Россиянең төрле төбәкләрендә татар теле дәресләрен алып бару өчен укытучылар һәм туган телебезне әйбәт белгән дин әһелләрен җибәрүне сорап, еш мөрәҗәгать итәләр. Бернечә дистә ел элек кенә Казанда югары белем алган татар егет-кызларыбызның башка төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез янына эшләргә китүен хәтерлибез. «Ул елларда республикабызның да, Казанның да дәрәҗәсе башкачарак иде. Бүген Татарстан да, башкалабыз да – әйдәп бара. Берәүнең дә республикабыздан чит төбәккә эшләргә чыгып китәсе килми, чөнки Татарстанда уңай шартлар тудырылган. «Үзегезнең кешеләрне җибәрегез. Укытып, кире кайтарабыз», – дип җавап бирәбез», – ди В.Шәйхразыев. Милли Шура рәисе дәүләт программасы нигезендә дәреслекләрне төбәкләргә тарату эше дәвам итүен әйтте.

Әсбапны төбәкләргә илтү өчен, Мәгариф министрлыгыннан лицензия алу мәслихәт. Бүгенге көндә 44 дәреслек сертификация үтә. Ярдәмлекләр да бар. Гариза белән мөрәҗәгать иткән төбәкләргә китапларны тәяп җибәрәләр. Моның өчен бюджеттан ел саен 3 миллион бүлеп бирелә.

Күп кенә зур шәһәрләрдә, һәр мөфтияттә диярлек мәдрәсәләр эшләп тора, мәчетләрдә дә белем бирү бара. Аларның кайберләрендә шәкертләр татар дәреслекләре буенча, ә беришендә башка телләрдә укытыла. Әгәр теге яки бу төбәктә, Диния нәзарәтләре булып, андагы мөфтиләр татарлар икән, мәдрәсәләр дә эшләп торса, Бөтендөнья татар конгрессы, бу җирлектә татар телен өйрәтүне, милли тәрбия бирүне мәҗбүри итеп куйган. Конгресста Диния нәзарәтләре белән эшли торган хезмәткәрне эшкә алганнар. Мөфтиятләрдә, мәдрәсәләрнең реестрын төзеп, укытуның бердәм уртак стандартлар кертеп, үзебезнең уку әсбаплары белән тәэмин итеп, гамәли күнекмәләр биреп, без бу эшләрне бергәләп алып барырга тиеш. Аңлашыла ки, Конгресс мөфтиятләр, мәдрәсәләр эшчәнлегенең дини ягына артык әчкә керүне максат итми. «Аның өчен мөфтиятләр бар. Безнең өчен иң әһәмиятлесе – татар тәрбиясе бирү һәм телебезне укыту. Бу безнең карар кабул итеп тормышка ашыра башлаган проектларның берсе», – дип белдерде Милли шура рәисе.

Быел Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов милли бәйрәмебез – Сабан туен әби-бабаларыбызның милли уеннары, гореф-гадәтләребез белән баетырга кирәклеген белдергән иде. «Интертат» электрон газетасы һәм «Татар-информ» татар редакциясенең баш мөхәррире Рәмис Латыйпов та Бөтенроссия авыл Сабан туйларына миллилек җитми, дигән фикерне белдерде. Шуңа да очрашуда Сабан туе төп темаларның берсе булды. Президентыбыз күтәргән мәсьәлә буенча инде эш башланган. Казан дәүләт мәдәният институтында сөйләшү дә булган. Бу юнәлештә Татарстан Мәдәният министрлыгы да эш алып бара, республиканың баш режиссерларын җыеп фикер алышулар да уздырганнар. В.Шәйхразыев бу уңайдан Сабан туйда татарлык, милли ризык һәм киемнәребез, борынгыдан килгән спорт уеннары кебек дүрт юнәлештә эш алып барылачагын әйтте. Сабан туйны үткәргәндә төп әһәмиятне татар гореф-гадәтен чагылдыруга бирергә ниятлиләр. Ат чабышы, баганага менү, бил алышу һ.б. милли уеннарның дәрәҗәсен күтәрү мөһим. Бабаларыбыздан калган күп кенә уеннарны да кире кайтару сорала. Әйтик, таяк тартышып көч сынашулар халкыбызда күптәннән килгән уен булган. Әмма соңгы елларда ул милли бәйрәмебездән югалды. Моннан тыш бәйрәмдә татар милли ризыклары тәкъдим ителергә тиеш. Сабан туйга милли киемне кайтару катлаулырак. «Ир-ат башына түбәтәй кия икән, ул милли кием кебек кабул ителә. Ә хатын-кызлар ничек киенергә тиеш?», – ди В.Шәйхразыев. Милли ризыкларны, ашларны пешереп чыгару зарур. 2023 елда федераль Сабан туе Әстерханда үткәреләчәк. Аңарчы Сабан туен үткәрү программасында үзгәрешләр, күрсәтмә-тәкъдимнәр брошюра булып тәкъдим ителәчәк. Без анда бөтен мөмкинлекләрне күрсәтергә тиеш. Шулай ук Сабан туен Россия төбәкләрендә үткәргәндә, бәйрәмгә шул өлкәнең гореф-гадәтләрен дә кертергә тиеш булабыз. Әйтик, кереш өлешнең Татарстан программасы 20 минут бара икән, җирле халык 12-15 минут чыгыш ясый, аннары ул уртак зур номер белән тәмамлана. Сабан туен башкача үткәрү кыен.

Соңгы елларда Ык буе авыллары Сабан туйлары гөрләп уза. Быел Казахстанда да беренче тапкыр Иртыш буе Сабан туе үтте. Милли Шура рәисе киләсе елдан Идел буе Сабан туен үткәрергә планлаштыруларын белдерде. Идел буенда Россиянең 15 төбәге урнашкан. Шул ук вакытта аңа өлкәләр аша уза торган 26 инеш коя. Гомумән, Россиянең милләттәшләребез гомер кичерә торган 41 төбәге Идел елгасы белән бәйле. Сабан туе халкыбызны берләштерә, башка милләтләргә дә татарларның кунакчыл икәнен күрсәтә.

Сөембикә КАШАПОВА

Шагыйрь җаны

(Поэма)

Айрат СУФИЯНОВ

1

... Күкләр күкрәп, яшен уйнап узды,
Күтәрелде өермәле давыл.
Шыбырдашты таллар. Елгаларның
Ярларына сукты дулкын шавы.
Картлар дога кылды:
«И-и- и, Илаһым,
Барчабызны, чорны ярлыкагыл!»
Түбә такталарын шыгырдатып,
Тупыл яфракларын шыбырдатып,
Кемне көтте, өмет күзен атып,
Михнәт чигеп арган ярлы авыл?

2

...Вөҗдан суты белән сугарылып,
Хаклык галәменнән кубарылып
Килде кешелеккә шагыйрь җаны
Бәйсез Сүзен
Җирдә әйтер өчен тугарылып...
Максаты зур, максаты нур иде,
Орлык иде уе изгелеккә.
Кара тирдә кайнап, һәр гамәлен
Юнәлдерде аклык, игелеккә.
Караңгыда кармаланып, язмыш
Камчысыннан ул кыйналды азмы?
Үткәннәрдә, әллә киләчәктә
Ул тилмергән ялгыз кайтавазмы?
…Хыялында йөрде гүзәл гамьле,
Камил, ямьле, милли таңның язы...
Чынбарлыкның чылбырлары чыңын
Күмә алдымы соң моңлы сазы?
...Гаҗиз калып, күпме кордашлары,
Чордашлары саулыгыннан язды...
Чыгырыннан чыккан фанилыкта
Нәфес колы – өстәгеләр азды.
Нәфес – сукыр.... хәят харитасын
Укый алмый... Ни күрергә язды?
Явызлыкка шагыйрь күнекмәде,
Күнекмәде канга, күз яшенә.
Битарафларны да өндәде ул
Үз хокукын саклау көрәшенә.
Ни сәбәпле җирдә кешеләр соң
Кызганусыз хөкем корбаннары?
…Үз-үзен дә яклый белмәүченең
Җимерелә бөтен корганнары…
Матдилекне югарыга чөеп,
Чикләнелгән мөмкинлегең сөеп,
Яшәп булмый үлемсезлек даулап.
Дөньялыкта вакытлыча отар,
Ахирәттә үзе җавап тотар
Дан казанган тиран, илләр яулап...
Күк гыйлемен кабат хәтеренә
Төшерергә теләп газапланган
Шагыйрь ни кылсын соң? Бәйсезлеге
Канатланган килеш кадакланган.
Шагыйрьләрен кайчан, кайсы дәвер
Бәһаләгән исән-сау чагында?
Азмы алар, азмы таланганнар,
Соңлап кына илдә танылганнар
Тынычлангач... үлем кочагында...
Күпме бөекләрнең җәсәдләре
Кәфенсез дә, ләхетсез дә килеш
Дога көтеп ята... каргышлардан
Каһәрләнмәгәнме бөтен иле?
Түбәнсеткән чарасызлык белән
Очраштылар, кавыштылар күпләр.
Эндәшмәде күкләр... йолдызлары
Караса да җиргә үрелепләр...
Чәчәкләрнең саф сулышын буып,
Коточарлык котсызлыктан туып
Күтәрелде өскә әрсез чүпләр...
Алар да соң яшәргәме лаек?
Эндәшмәде күкләр...

3

Ант эчкәнме бәндә, явыз шайтан
Коткысына күндәм авышырга?..
Ишетмәде гасыр, тигезлеккә
Өндәп туган шагыйрь тавышын да.
Ничек кешелекне кадерләргә
Торган акыл белән кавышырга?
Карагруһлар аның канын эчте,
Суырдылар шашып җан сутын да.
Чорга яраклашмый дөрләп янды,
Янганда да туңып ул уянды
Гомеренең һәрбер минутында...
Кара ялган түгел, хаклык йөрде
Вөҗүдендә, бөтен булмышында.
Гаделлекнең шәүләсен дә күрми
Өзелмәсме соңгы сулышы да?..
Кысаларга сыймас талпынышы
Тайпылмады ирек мәсләгеннән…
Берләшмәде халкы гыйбрәт алып
Аккош, кысла, чуртан мәсәленнән.
Көнлекчеләр, сатлыкҗаннар баскан
Заман шәйләмәде барлыгын да.
Ә ул барыбер,
Яраклашып, койрык болгый-болгый,
Ялланмады фикер тарлыгына.
Коллык колашасын читкә какты
Тугрылыгы дала кылганына…
Туган теле кимсетелгән чакта,
Ничек шөкер итсен булганына.
Үзе булып, үзгә яшәү ямен
Җыр итсә дә олы ниятендә,
Аңламады: нинди урын тотты
Кешелексезлек җәмгыятендә...
И-и-и, дөньялык… иминлеккә дошман
Кан эчендә ерткыч кануннарың.
Табигатьнең бөтен байлыгын да
Йомарлады битсез каруннарың.
Җиңдеме соң шагыйрь? Юк, җигелде
Йөк атыдай сынау арбасына.
...Башы черек балык кылчыклары
Күзләренең ачы алмасына
Кадалдылар... (ничек калсын читтә?)
Ул төшенде: ерткыч бу мохиттә
Тиздә килеш яши алмасына.
Кайчан гына кайтыр адашканнар
Тәүбә итеп
Нур-балкышлы юлдан, Алласына?
Лаексызлар – түрдә... Алар – түрә...
Изелгәннәр басып аягүрә
Калтыранып карый кара гүргә.
Кем уянып, аермачык күрә?
Итагатьне, Акыл, Намусны да,
Буа-буа золым күперенгән.
Дин көчәйде, диләр... хакыйкатьтә
Кешедәге ИМАН үтерелгән...
Тәмугларга очып төшмәбезме
Чыга алмый сират күпереннән?
Шул микәнни сайлау хокукыбыз?
Өмет учаклары сүндерелгән...
Утлы кузлар беткәнме соң чәчрәп?
Җанын асрау читлегендә чәчәп,
Көн күрергә гавам күндерелгән.
Тамырларга төшкән сорыкортлар
Ишәйгәндә, кайсы ил терелгән?
Фаҗигабез – өнсез башыбызны,
Сыйпый-сыйпый кабер ташыбызны
Каршылыксыз без букәнгә куйдык,
Изге, асыл кыйммәтләрне җуйдык
Күкләр тарафыннан иңдерелгән.
Күпме мөмкин артка чигенергә?
Чигенүнең соңгы чиге – упкын.
Аңкауда тел корый... Без – Ватансыз.
Садагыбыз – уксыз, тән – калкансыз
Кай тарафта ауный кылычсыз кын?..

4

Ышанды ич шагыйрь матурлыкның
Җаннарны да коткарачагына.
Күк чагылган чишмәләрнең җыры
Илһам өрде авыл баласына.
Җиләк җыеп урманнарда йөрде
Һәр бөҗәккә туганнарча дәшеп.
Иркәләнде хуш ис бишегендә,
Тирә-юньгә баллы хис өләшеп.
Күкрәгенә киңлек керә иде,
Болыннарда печән күбәләсә.
Җир – түшәгем, дисә, кояшлы күк
Мәңге ишелмәслек түбә ләса!
Көмеш чишмәләрнең суы белән
Кушып эчте сабый чагылышын.
Тоемлады тамырлары буйлап
Тереклекнең кайнар кан агышын.
Матурлыкка хезмәт иттеме ул?
Өлгермәде… соңарды ла бугай…
Аңа рәнҗептер шул тынып калды
Баш очында сайрап очкан тургай...
Сары төскә керде чикерткәле,
Күбәләкле, мәтрүшкәле тугай.
Сәбәп юкмы? Дөнья төренмәде
Сәгадәтле, сөенечле нурга.
Бәхилләште ул яраткан көйләр,
Сирәкләнде авылларда өйләр,
Ераклашты кыңгыраулы дуга...
Айга карап газиз кавеменең
Ак бүресе шуңа улый иде.
Ятимсерәп туган нигезендә
Көне-төне шөршек* елый инде...

5

Өммәтенең мәгърур, шәүкәтле дә,
Газиз Ватанлы да чорларында
Яшәмәде... Шуңа үкенечле
Дала каны үкси җырларында.
Җил дә, җир дә, күл дә, урман, су да,
Илбасарлар, гуҗлар карынында.
...Һәр әгъзаңны телгән яман чирдән
Нинди ысул белән арынырга?
Өметләнде: югалтканнар кайтыр,
Юатыр да диеп, алсу таңда.
Дәва көтте изге теләк юллап,
Хыялларын яхшылыкка юрап,
Ай, йолдызлар күктә балкыганда.
Уңай якка заман үзгәрмәде,
Күзләрдәге яшь кипмәде һаман.
Ата улын, кыз анасын белми,
Җиттеме соң әллә ахырзаман?
Ачылмады бәхет йозаклары.
Имин көннәр никтер озаклады…
Адым саен мәкер тозаклары…
Корыса да күптән улаклары,
Якын инде соңгы туй атлары,
Бәгырьләрне айкый тояклары…

6

Арып-талып әйтте: «Эзләгәнем
Табылмады, Раббым, Җир йөзендә.
Уңай якка үзгәртерлек таш та
Салмадыммы тормыш нигезенә?
Вазыйфамны үти алмый китәм,
Бата-бата хәсрәт диңгезендә...
Йөрәкләрне кузгатмадымы соң,
Кабынырлык куз атмадымы соң
Асыл хакыйкатькә тиң Сүзем дә?..
Хак юлына басмаган да токым,
Тәүбә биген ачмаган да токым
Алтын эзли шайтан мөгезендә.
...Күрә торып, берни эшли алмыйм,
Гаеплемен бугай мин үзем дә.
...Олы үкенечем – эзләгәнем
Табылмады, Раббым, Җир йөзендә...»

7

Күкләр күкрәп, яшен уйнап узды
Күтәрелде гарасатлы давыл.
Шыбырдашты таллар... елгаларның
Ярларына ауды дулкын тавы...
Дөнья сыйган кемнең моңлы җанын
Бакыйлыкка син озаттың, авыл?!
Теләктәшлек көткән йөрәкләргә
Наз, мәрхәмәт ошбу җаннан агыл!
Хәят яратылган гүзәл көннең
Ак сулышы, исәннәргә кагыл!
...Картлар дога кылды:
«Йа Раббым, Син
Һәммәбезне... чорны... ярлыкагыл!..»

* Шөршек – өй чикерткәсе.

Чаллы.

Газинур МОРАТ: «Кеше исемне бизәргә тиеш»

Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай премиясе лауреаты Газинур Морат Кукмара районының Зур Сәрдек авылында туган. Төрле елларда «Татарстан яшьләре» газетасында, «Ялкын» журналында, «Идел» журналында, «Мәдәни җомга» газетасында эшләгән. Соңгы елларда Татарстан китап нәшриятында эшләп, быел 63 яшен тутырып, пенсиягә чыккан.

– Пенсиягә чыгуга ялга киткәнсез икән, Газинур абый.

– Әйе, мин – хәзер профессиональ пенсионер.

– Гадәттә кеше, пенсиягә чыккач, эшенә теше-тырнагы белән ябыша...

– Профессиональ пенсионер булуның минем өчен берничә сәбәбе бар. Үземнең бик нык арыганымны сиздем: мин 41 ел буе гел бер эш белән шөгыльләндем – кульязмалар укыдым. Адәм баласы өчен 40 ел хезмәт стажы бик күп инде ул: үзен сиздерә башлады. Хөкүмәт пенсияне юкка гына бирми икән адәм баласына. Әлбәттә, пенсия яше элек, Сталин заманында, башкачарак билгеләнгән булган, хәзер халыкны «яшәрттеләр» бит. Чыннан да, нindидер бер чиккә килеп җиткәч, кеше үзендә арыганлык сизә икән.

– Акча җитми башласа, кире нәшриятка кайтуыгыз да мөмкинме? Ял иткәннән соң, теге «индексация чорын» узганнан соң, алга таба тагын кульязма укый башлаячаксызмы?

– Шулай булып чыга инде. Үз иҗатың белән генә тормыш итү кыенрак. Шигърият һәм проза белән булмый да булмый инде. Драматургия белән була торгандыр, ихтимал.

– Җыр тексты язып бераз очын очка ялгарга мөмкиндер әле, ә сез аның белән дә мавыкмадыгыз кебек...

– Ни кызганыч, җырчы шагыйрь булырга туры килмәде шул. Шулай да кәеф килгәндә җырлаштырам мин үзе. Яшьрәк чакта бер җырлап җибәргәч, Ркаилнең: «Син профессияне дөрес сайламагансың бугай, сиңа җырлыйсы калган», – дип әйткәне дә булды. Җыр, дигәч, искә төште: мин 7 класста укыганда, нотага карап, музыка уен коралында уйнарга да өйрәндем.

– Үзлектән нота өйрәндегезме?

– Анысына өйрәттеләр. Безнең авылга ул вакытта бик билгеле музыкант, композитор, оркестровка буенча зур белгеч Мәсгут Латыйпов килде. Ул безнең мәктәптә укучылардан тулы бер оркестр оештырды. Оркестрда 30лап бала. Аның бит уен кораллары хәзер дә алтын бәясе тора, ул вакытта да кыйммәт торгандыр. Шулай итеп безне музыкага өйрәтте ул. Язучылар арасында мин – бердәнбер нота таный торган кеше, дип, кайвакытта мактанып та куйгалыйм.

– Нигә алайса җыр яза торган шагыйрь булып китмәдегез икән?

– Менә, нишләптер, безнең буында җыр сәнгатенә җитди игътибар булмады.

– Турысын әйткәндә, түбәнрәк сәнгать саналдымы?

– Бәлки, шулай булгандыр да инде. Дөресен әйткәндә, элек җыр текстлары нигездә шактый примитив иде бит. Аны уртакуллар яза, дип санадык.

– Шуңа да җыр текстлары язып «вакланмадыгыз» инде!

– Ләкин, тора-бара, җыр тексты язучы «кәттә» авторлар да килеп чыкты. Алар, чыннан да, җыр сәнгатен югары дәрәҗәгә күтәрде. Без затлы музыка тыңлап үстек: радио көне буе «җырлап тора», аннан Мөнирә Булатова, Хәдичә Гыйниятова, Зөләйха Хисмәтуллина, Илһам Шакиров, Рәшит Ваһапов, Габдулла Рәхимкулов, Рәйсә Билалова җыр суза. Ә композиторлары ни тора! Татар җыр сәнгатенең алтын чоры булган ул, кыскасы.

Бәлки, безгә дә җыр текстлары язуга җитди эш итеп карап, аның белән ныклап шөгыльләнергә кирәк булгандыр. Юкса без композиторлар белән һәрвакытта да якыннан аралашып яшәдек. Әйтик, Фасил Әхмәтов белән. Өстәвенә, ул минем якташым да иде. Ләкин; «Фасил абый, минем шигырьләргә дә җыр язып карагыз», – дип бер сүз катканым да булмады. Кыенсыну да булгандыр инде, бәлки. Фасил абый – гениаль композитор ул, чын татар моңсары. Әйтәм бит инде, кемнәр белән генә аралашмадык... Мөмкинлекләр дә бар иде ул вакытта: матбугатта эшлисең, анда композиторлар да килә. Шушы эшкә алынмау – безнең эшләп җиткермәгәнлек, дип исәплим инде, нишлисең. Безнең юллар үкенечләр белән түшәлгән...

– Газинур абый, сезнең белән 90 нчы еллар турында сөйләшәсем килә. Сез милли хәрәкәттә актив катнашкансыз. Ирек мәйданында ачлыкта да утыргансыз әле.

– Булды андый «гөнаһлар»...

– Хәзер ул чор турында нәрсә уйлыйсыз? Кайда ялгыштык? Нәрсәне дөрес эшләдек? Хәзерге күзлектән уйланып карыйк әле.

– Ул заманны, дөресен әйткәндә, татарның үзенә күрә «алтын чоры» дип исәплим. Гасырлар буе күңелдә җыелып килгән ихлас сүзләр дөньяга чыкты. Татарның, бәлки, беркайчан да ул кадәрле бергә җыелганы булмагандыр. Ул вакытта Ирек мәйданының исеме чыннан да җисеменә туры килеп тора иде, бөтен митинглар шунда үтте. Ул чакта 35-40 градус эссе... асфальт җеберлек эсселек иде... 90нчы елның май ае. Ул турыда хәзер уйларга да ярамый бит инде... Һәм аның безнең яшәешкә бик зур йогынтысы, тәэсире булды, дип исәплим мин үзем. Ул суверенитетның җимешләре шактый мул булды. Федераль үзәк белән акча бүлешү мәсьәләсендә дә беркадәр гаделлек торгызылды. Чөнки, акча булмаса, бернәрсә эшли алмыйсың – шул вакытта безнең җитәкчеләр шартнамәләр төзеп калдылар. Артында халык тора икән, җитәкчелек һәрвакытта зур эшләр майтара ала. Булдыра, теләсә…

> *Мотлак ялганга корылган илдә сәясәтчеләр генә дөрес сөйли.*
>
> **Газинур МОРАТ**

– Теләсә...

– Ул вакытта теләк тә булган, димәк. Татарстанда бөтен авылларны газлаштыру – үзе гаҗәеп хәл бит инде, ул, гомумән, тормышны үзгәртте. Юллар бөтенләй сикәлтәле иде, яхшы юллар салынды. Юл булмаса, дөнья да бармый бит. Ул елларда тузган торак программасы буенча күпме халык фатирлы булды! Боларның бөтенесенең нигезендә 90нчы елларның йогынтысы сизелеп тора. Шуңа күрә без юкка гына «Азатлык» дип кычкырып йөрмәгәнбез, күрәсең.

– Ачлыкта утыручыларның берсе ничек сез булып чыктыгыз соң ул вакытта?

– Ничек дип, мин ул вакытта «Идел» журналында эшли идем. Гомумән, милли ислахның башында торды инде ул журнал. Чыга башлап, 1-2 ел эчендә, ул иң популяр, үз сүзен кистереп әйтә торган, моңарчы матбугатта беркайчан әйтмәгән сүзләрне кыеп әйтә торган басмага әйләнде. Без ул вакытта яшьрәк тә, әтәчрәк тә бит инде. Баш мөхәррирнең фатихасы белән (баш мөхәррир Фәиз Зөлкарнәй. – авт.), муенга «Идел» журналы дигән язу элеп, рәссамнан «Ачлык», «Азатлык» дип яздыртып, Әхәт Мушинский белән икебезне редакция озатып калды.

– Газинур абый, язучының биографиясе бай булырга тиеш, диләр.

– Биография ике төрле була. Аның берсе – текст булып хезмәт кенәгәсенә языла торганы. Була күңел биографиясе. Язучыга, беренче чиратта, күңел биографиясенең бай булуы кирәк. Ул күпмедер дәрәҗәдә «өстән» дә бирелгән. Аннан соң, яшь чакта нәрсә укыйсың бит әле. Күңел биографиясен яшь чакта алган гыйлем белән, укыган әдәбият белән дә баетып була.

Элек безнең төп эшебез, әлбәттә, китап уку иде. Телевизор юк, компьютер юк, интернет юк... Шул эти-әнигә булышу, дәрес әзерләү (әзерләсәң инде) һәм китап уку. Ул вакытта халык укуга, гомумән, һәвәс иде, китап уку культурасы бар иде. Китапханәбез дә шактый бай иде, Ходайның рәхмәте. Мин, дәреслекләрдә булган авторлар белән генә чикләнеп калмыйча, әдәбиятта яңа сүз әйткән шагыйрьләрне эзли башладым. Шул вакытта кулыма дәфтәр калынлыгы гына кечкенә шигырь китаплары килеп эләкте. Алар инде бүген атаклы шагыйрьләр – Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Разил Вәлиев. Аннары Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов китапларына юлыктым. Үзем эзләп таптым мин аларны. Талантлы шагыйрьләрне үз акылым белән капшанып эзләп таптым. Менә шушы мавыгулардан үзем дә әкрен генә шигырь калыплый башладым. Гәрчә минем балачакта шигърият белән дуслык юк иде. Мин бала чакта яшәү белән үлем арасында калдым. «Менингит» дигән бик алама чирнең иң авыр формасы белән авырдым. Бу – баш миенең ялкынсынуы. Андый авырудан йә үләсең, йә гарип каласың... яки инде, «башың китеп», минем кебек шигырь яза башлыйсың. Миңа шунысы язган булып чыкты. Табибләргә рәхмәт, саклап калганнар. Фәрештәләрнең «амин» дигән сәгатенә туры килүдер инде бу.

Әле менә күптән түгел генә белдем: мине исән калдыруда бер бик хөрмәтле белгечебез – Зиннур Закировның өлеше зур булган. Ул үзе бик төпле публицист та, ә беренче чиратта – балалар табибе. Без аның белән күрше авыллардан. Бер гәпләшеп утырганда, мин аңа 3-4 көн комада ятуым турында сөйләп киттем. Умыртканы кы-

тыр-кытыр китергәндә уянып алам, ләкин авыртуны сизмим. Шул вакытта гәүдәм янында ак халатлы кешеләр йөргәнне өстән карап торган чаклар да булды. Табибләр аны «клиник үлем» дип атый инде. Шунда Зиннур абый әйтеп куйды: «Газинур, синең умыртка сөягеңне кытырдатучы мин идем бит ул», – диде. Арка миеннән анализ алганнар икән. 45 көн дәваланып яттым. Кадалган уколларны санасаң, бөтен гомергә җитәрлек булгандыр инде ул – хәтта утырып тора алмый идем. Шушындый хәлләр дә кичерелде. Бу – Ходайның бер сынавы булгандыр. Баш миенең зырылдап әйләнеп китүе, шулай итеп, мине шигырь язар көнгә калдырды.

– Газинур абый, без сезне үтә дә гадел кеше дип беләбез. Әйтик, бер елны гранттан баш тартуыгыз – сезнең өчен кечкенә генә тормыш мизгеледер, ә безнең өчен ул гаҗәеп хәл булды. Бездә бит грантны алуын алалар, ләкин еш кына эшләмиләр. Сез бит ул грант таләпләренә туры килә торган әсәрләрне бик җиңел яза ала идегез.

– Гадел дигәннән, гаделлек әдәбиятта гына түгел, бөтен җирдә кирәк инде ул. Хәзер бәяләнми генә... Мин бит үзем – гел өлкән кешеләр сүзенә колак сала торган беркатлы адәм. Үз гомеремдә беркайчан да грантлар алу мөмкинлеге турында ишеткәнем дә юк иде. Гомумән, мине иҗатның матди ягы әллә ни кызыктырмады. Шундый форсат тугач, дуслар: «Әйдә, катнашмыйсыңмы?» – дип, миңа хәбәр салды. «Ярар, – минәйтәм, – сез әйткәч катнашмый ярамас», – дидем. Документлар да тутырып җибәрдем. Шуннан соң 20 ел буе бергә эшләгән, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире булган Зиннур Мансуровка шылтыраттым. «Зиннур абый, син катнашасыңмы?» – дип сорадым. Кире җавап ишеттем. Миңа шул җитә калды. Ничек тыңламыйсың 20 ел буе баш мөхәррирең булган кешене? Автоматик рәвештә шулай килеп чыкты ул – баш тарттым. Аннары кызган табага бастырып сүктеләр, әлбәттә...

– Ркаилләрме?

– Ркаилләр түгел – Ркаил. Ул тәкъдим иткән иде миңа анда катнашырга. «Язасың килмәсә, үзем язып бирә идем мин сиңа», – дип, үземне оялтты да әле. Шулай булды! Бу – бернинди батырлык та түгел... Ә аннан соң «син барыбер конкурсларда катнашмыйсың» дип, жюрига кертә башладылар. Мин хәзер почетлы жюри булып йөрим. Телләрне үстерү комиссиясе химаясендә башланган ябык әдәби конкурста да жюри әгъзасы иттеләр. Бу юлы миңа проза әсәрләре генә укырга туры килде. «Син бит проза язмыйсың, каян беләсең?» – дигәнне ишеткәләгән дә булды, билгеле. Кыскасы, мин повесть һәм хикәяләр укыдым. Жюрида утыру – бик җаваплы вазыйфа. Гомумән, анда ялгышырга ярамый. Нәүбәттәге конкурста да жюрига дәшсәләр, объектив булырга тырышырбыз, иншалла. Әлеге конкурс әдәбиятны гел дә җанландырып җибәрде. Шөкер, язучыларыбызның потенциалы зур, әчке энергиясе ташып тора әле. Мобилизация үзенә күрә...

– Мобилизация?

– Мобилизация – каләм әһелләрен уртак эшкә берләштерү бит инде ул. Мотивация булгач, язучылар шундук хәрәкәткә килә башлый. Бер ел эчендә каләмдәшләребез менә дигән романнар, повестьлар, хикәяләр, шигырьләр, поэмалар иҗат итте...

– Укучысы гына булсын.

– Анысы – башка мәсьәлә. Иң мөһиме: язучыларның күңел төшермичә иҗат итүе кирәк. Чөнки язучылар да инде борын салындырып, «бетәбез» дип торса, нишләмәк кирәк. Шөкер, яшьләребез дә, урта буын да, өлкән язучыларыбыз да чагыштырмача кыска арада әдәбиятны алга этәрә торган әсәрләр иҗат итә алды.

● Язучылар – халык арасында. Уңнан – сулга: Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Рабит Батулла, Газинур Морат.

– Гаделлек, намус турында сөйләшә башлаган идек. Матур гына читкә китеп бардыгыз...

– Авыз тутырып «мин намуслы» дип утыру – дөрес гамәл түгел инде ул. Һәрвакыт намуслы саклап бетерергә тә булмый торгандыр. Ләкин иҗатта, үзара мөнәсәбәтләрдә гадел булу кирәк. Алдашмау, иптәшеңне авыр хәлгә куймау.... Гомумән, ялганлауны яратмыйм. «Алдакчылар партиясе»нең «генераль секретарьләре» белән мин үзем һәрдаим аралашып яшим. Алардан «кыен ашаган» чаклар да булды. Ләкин нинди генә хәлдә дә, таш атсалар да, аш белән җавап кайтарырга кирәк. Кешегә зыян салу, үчләшү, үпкә саклау мөселманның әдәп-әхлак кысасына да сыймый. Мөселманга 3 көннән артык үпкәләп йөрергә, гомумән, ярамый.

– Ягъни үзегезгә зыян салган кешеләргә дә үпкәләмисезме?

– Юк, үпкәләмим. Заманында бик авыр хәлләрдә калдырган кешеләр дә булды, әлбәттә. Аларның күбесе бу дөньяда юк та инде. Күңелең чиста, үзең ихлас булсаң, Ходай Тәгалә үзе сиңа ярдәм итәргә тырыша кебек тоела. Көфер сүз сөйләмәсәң... Намаз укыйсың да, «Аллаһу әкбәр!» түгел әле. Намазның ни-нәрсә икәнен белмәгән килеш тә намус ияләре була. Минем өчен әти-әни намус ияләре иде. Намаз ияләре түгел иде алар. Чөнки икесе дә дәһрилекнең коточкыч чәчәк аткан чагында тәрбия алып үскән. Алар, әлбәттә, намазга ук барып җитә алмады. Ләкин намус иясе булып яшәделәр. Шуңа күрә аларның сүзен васыять итеп кабул кылып яшәп ятам, Аллага шөкер! Намус дигәч, әллә кайчан язылган бер шигырь юлы искә төште әле: «Намуслы яшәвең җирдә – үзе, бәлки, батырлык». Дөресен әйткәндә, чыннан да, батырлык икән бит ул. Батырлыкка әйләнде дә китте хәзер. Безнең вәзгыятьтә – бигрәк тә. Ләкин «намус категориясе» беркайчан да үзгәрми. Намуслы булуның күләме булмый. Ул йә бар, йә – юк. Әз генә намуслы булып булмый.

– Газинур абый, күптән түгел сез «халык шагыйре» булдыгыз, бу – ниндидер йөкләмә бирәме? Халык шагыйре булгач, нинди уйлар белән уянып китәсез? Халык шагыйре белән «просто» шагыйрь Газинур Морат арасында аерма бармы?

– Гел дә юк, дисәм, бигүк дөрес булып бетмәстер инде.

– Күкрәкне киеребрәк йөри башладыгызмы?

– Менә монысы холкыма бөтенләй дә туры килми, Рузилә. Мин – бик пессимист кеше. Өстәвенә, оптимистлар начар яза, дигән гыйбарә дә бар. Әйе, мин – табигатем белән пессимист. Вөҗүдем белән пессимист. Минем беркайчан да үз исемем астына мактаулы исем өстәп язып куйганым юк. Мактаулы исем кешене түгел, ә кеше ул исемне бизәргә тиеш.

– Аның каравы, хатыныгыз сөенгәндер – халык шагыйре хатыны булу начар түгел бит...

– Шул хатын сөенсә генә инде. Бәлкем, дуслар да сөенгәндер. Каләмдәшләргә рәхмәт. Халыкка танылуга караганда каләмдәшләрең арасында сан алу күпкә кыенрак. Мине бертавыштан тәкъдим иттеләр, хупладылар. Рәхмәт аларга.

– Каләмдәшләр, дигәннән, Берлеккә рәис сайлаганда, еш кына интригалар да була. Андый мөрәҗәгатьләр сезгә дә булмый калмагандыр, дип уйларга кирәк.

– Юк, миңа бер генә кандидатның да шалтыратып әйткәне булмады. Беркайчан да. Чөнки алар минем бер генә кеше өчен тавыш бирәчәгемне яхшы белә. Күреп торасыз: эшли башлавына ел ярым гына булса да, Ркаил Зәйдулла әллә нилар майтарырга өлгерде инде. Хәзер бит Язучылар берлегендә ремонт башланды. Хәтта Язучылар йортының фундаментын казыганнар, әле фундаментка ук төшеп җиткән кеше юк иде.

– Кайчандыр үзегез алып йөргән бина, әйеме?

– Әйе. Туфан абый җитәкчелегендә. Туфан Миңнуллин – мин дөньяда күргән беренче тере язучы иде. Каядыр 70 нче еллар башында безнең авылда иҗат командировкасында ярты ел ятты ул. Элек бит шундый мөмкинлекләре дә бар иде язучыларның. Хәзерге грант кебек бер нәрсә булгандыр инде ул. Туфан абый, мәктәбебездәге укытучылар тормышын өйрәнеп, «Үзебез сайлаган язмыш» дигән пьеса язды. Иң беренче премьерасы да безнең мәдәният йортында булды. Туфан абый безнең авылны бик үз итте. «Кама Тамагында тумасам, Кукмарада туган булыр идем», – дия торган иде. Соңрак минем туган нигездә дә булды ул. Безгә кайттык. Аның үзенә күрә бәхилләшеп, саубуллашып йөрүе булгандыр, дип уйлап куйдым соңыннан. Мәктәптә очрашу үткәрдек. Әни бик гаҗәпләнде инде: «Син чын Туфанмы соң?» – дип, килеп, үзен тотып-тотып карады. Туфан абый белән бик күп аралаштык без. Рухы шат булсын. Безгә ышанып, туган авылына мунча салырга да чакырган иде ул. Кайттык, эшләдек. «Да, егетләр, мунча килеп чыкмады, сез төзегән мунчадан келәт ясарга туры килде», – диде соңыннан. Җылы тотмый икән. Без бит инде чын осталар түгел.

– Кит инде, Газинур абый, Кукмара тумасы була торып, сез дә шулай диеп торсагыз! Иң шәп балта осталары Кукмарада түгелмени?!

– Миңа бирелмәгән шул. Әти оста иде, энекәш оста. Китап укып әллә кая китеп булмый шул.

– Законнарга туры китереп, бүгенге вәзгыять турында нәрсә әйтә аласыз? Бүген «тел», «милләт» дип сөйләшеп йөрү икенче планга калдымы? Бөтенләй уңайсыз кебек түгелме ул темага сөйләшү?

– Юк, уңайсыз түгел. Безнең халык үз гомерендә ниләр генә күрмәгән! Язучыларыбыз, шагыйрьләребез мылтык түтәсенә куеп иҗат иткән. Фатих Кәримне алыйк, Җәлилне! Гаҗәп бит инде. Алар телне, халыкны һәрвакыт беренче урынга куеп яшәгән, иҗат иткән. Туган тел дә, аның яшәеше дә, әдәбиятыбыз, мәдәниятебез дә беркайчан да икенчел була алмый. Халкыбыз нәрсә генә күрсә дә, безнең бабалар иманнарын сатмаган. Кемнәрдер саткан да инде, ләкин алары – хурлыклы искәрмә генә. Бу темага билгеле бер гыйбарә белән нокта куяр идем. Европа халыклары арасындагы «теләсә кайсы сугыш асылда гражданнар сугышы булып тора» дигән сүз бар. Бер акыллысы шулай дип әйтеп калдырган. Әлбәттә, Европа коточкыч күп кичергән сугышларны. Әмма ул, тора-бара, цивилизацияле үсеш юлына аяк баскан. Берләшкәннәр. Без, гомумән, тынычлык тәрбиясе алып үскән буын. Безне «миру – мир» дип өйрәттеләр. Дөнья, барыбер, аңына килер – мин шуңа ышанам.

– Мөһаҗирлеккә ничек карыйсыз? Киткән кешеләргә мөнәсәбәтегез?

– Мөһаҗирлектән безнең халыкның беркайчан да башы чыкмаган, үзең беләсең. Безнең халык бәхет эзләп тә күп йөргән инде. Ул аңа күнеккән, дөресрәге, күнектерелгән. Шуңа күрә ул инде чәчрәп тә чыкмый. «Баш саклау» дигән нәрсә аның геннарына салынган. Һәрхәлдә, бу вәзгыятьнең тиз арада җайланасына өметләнергә генә кала.

– Язучы җәмгать эшлеклесе буларга тиешме, әллә аңа язып кына утырса да буламы?

– Язып кына утырган кешене дә гаепләп булмый, ләкин безнең татар язучысына гомер бакый, әдәбияттан тыш, башка вазыйфа да йөкләнгән. Әнә Тукайны кара, Фатих Әмирханнарны кара, Дәрдемәндне кара, Исхакыйны кара – бөтенесе зур җәмгать эшлеклеләре булган. Язучы ул, дөресен әйткәндә, дәүләте булмаган халыкның дәүләте. Туфан Миңнуллин әйткән сүз ул. «Тукай – ул безнең дәүләтебез», – дигән иде ул соңгы чыгышында. Шуңа күрә халкыбыз Тукайга сыгынып яши дә бит инде.

Әңгәмәдәш -
Рузилә МӨХӘММӘТОВА

intertat.tatar

Циникларча мөнәсәбәт

Россия Президенты В.Путин «Россия-1» каналында чыга торган тапшыруда журналистның, Украина белән мөнәсәбәтләрдә Россия үзен Көнбатыш илләре кебек үк циникларча һәм нәзакәтле дә итеп тота алмас идеме әллә, дигән соравына: «Алмас иде! Бездә башка философия, тормышка вә кешеләргә башка мөнәсәбәт», – дип җаваплаган. Ә сүз нинди мөнәсәбәтләр турында бара соң? Моны аңлау өчен, ишарәле кайбер фактларга тукталыйк. Украина Президенты В.Зеленский узган атнада Вашингтонда АКШ лидеры Джо Байден белән сөйләшүләрдә катнашты һәм Конгресста чыгыш та ясады. Байден аны «ел кешесе» дип атаган, Украинага тынычлык теләве турында белдергән һәм аңа 1,85 млрд долларлык ярдәм кысаларында, ракеталарга каршы нәтиҗәле көрәшү өчен «Patriot» комплексы бирәчәге турында әйткән, алга таба да ярдәмнән аермаска вәгъдә иткән. Сенат исә икенче көнне 2023 ел өчен 1,7 трлн доллар күләмендә бюджет проектын хуплаган. Ә анда 2023 елга Украинага 45 млрд долларлык ярдәм каралган. Кремльдә бу сәфәр вә сөйләшүләр ачыну хисләре генә уяткан. Ә Украинага Мәскәүнең мөнәсәбәте нинди булуын РФ Саклану министрлыгы вәкиле генерал-лейтенант И.Конашенков хәбәрләреннән һәр көнне һәм кат-кат ишетеп торабыз.

Соңгы вакытта медиа-чараларда Кремльнең төрле вариацияләрдә, «без Украина буенча сөйләшүләргә әзер, Киев кенә һаман киреләнә» кебек фикерен дә еш ишетергә туры килә. Узган атнада илдә хәрби реформага да старт бирелде. Ә бу инде Кремль тактикасындагы үзгәрешләрнең сәбәбенә дә ачыклык кертә.

Атна вакыйгаларыннан игътибарны шулай ук: ЕСның газга өске бәя чиген рәсми төстә билгеләве; АКШ Сенатының Россия активларын Киев файдасына конфискацияләү мөмкинлеге бирә торган төзәтмәләрне хуплавы; Венгриягә тиешле 22 млрд евро күләмендәге ярдәмне Европа комиссиясенең туктатуы; РФ Президентының парламентка еллык юлламасы һәм ел ахырында үткәрелә торган «Туры линия»нең яңа елга күчерелүе; Европа Шурасы рәисе Шарль Мишельнең БМО Куркынычсызлык Шурасында Россиянең әгъзалыгын туктату тәкъдиме белән чыгуы; В.Путинның Чечня башлыгы Р.Кадыйровны Александр Невский ордены белән бүләкләве һ.б. җәлеп итә.

Фоат УРАЗАЙ.

Яшәү белән үлем арасында

(Автобиографик повестьтан)

(Ахыры.Башы 50 нче санда).

– Әйе, үлде, үтерделәр. Шәп дус иде. – Миша бераз тынып торды. Аннары: – Менә уң кесәмнән ал. Үзеңә дә төр, миңа да төреп бирерсең, – диде. – Йөрәк яна, бәлки, бераз файдасы булыр.

Без тәмәке төреп тартып җибәрдек. Тиз арада Мишаның тәмәкесе кулдан-кулга йөреп китте. Тәмәке, ничектер, кешеләрне җанландырып җибәрде. Кайсыдыр, көлә-көлә, анекдот та сөйли башлады.

Тәмәке төтененә өйрәнмәгән Миша бер суыру белән буыла-буыла ютәлләргә тотынды. Маңгаендагы кан тамырлары бүртеп чыкты. Йөзе кызарды, күзләрендә яшь тамчылары күренде. Шуңа карамастан ул тәмәкене тагын берничә мәртәбә суырып эченә алды да, башын противогаз сумкасына куеп, йөзен кулы белән каплады. Бераздан ютәле басылды, һәм Миша сабый бала кебек эреп йокыга китте.

Кич булып килә иде инде. Болай да караңгы төрмә бүлмәсе тагын да караңгылана төште. Тәрәзәләр ватылып беткән. Немецлар аларны чәнечкеле тимерчыбык белән челтәрләп куйганнар. Тәрәзәләрдән ишегалды һәм лагерь капкасы күренеп тора. Лагерьга әледән-әле машиналар килә, тоткыннарның саны һаман арта бара. Алар инде бүлмәләргә сыймыйлар – тышта, ачык һавада, төркем-төркем булып җыелып торалар. Яралылар стена буйларына сыенып, ыңгырашып яталар. Кемнәрдер:

– Кем Мәскәүдән?

– Кем Туладан?

– Кем Харьковтан? – дип кычкыра.

Алар шулай үзләренең якташларын, дусларын эзлиләр. Һәм шунда ук:

– Мин Мәскәүдән.

– Мин Туладан, – дигән тавышлар ишетелә.

Бу тавышлар караңгы төндә адашкан кешеләрне хәтерләтә. Куркыныч та, кызганыч та булып китә.

Капка башында прожектор утлары кабына. Аларның нурлары, ак елан кебек, ишегалдына, бина стеналарына кинәт кенә сузылалар да яңадан ояларына, тимер тартмаларга кереп югалалар.

Яңа гына сугыш кырыннан тотып китерелгән кеше үзен ниндидер авыр төш күргән кебек хис итә. Аң бернәрсәгә дә җавап бирми. Күзләр зур булып ачылган. Ләкин алар бернәрсәне дә күрмиләр кебек. Вакыт уза, һәм, вакыт узган саен, бу тоткынлыкның авыр кайгысы кешене баса бара. Әсир солдат әкренләп газаплы уйларга чума. Ул, читлеккә ябылган кош сыман, башта, бу хәлгә килешә алмыйча, арлы-бирле сугыла. Кая барса да, аны чәнечкеле тимерчыбык ураган, йөзенә салкын тимер көпшәләр карап тора.

Әсир солдат, кая гына карамасын, башына мөгезле каска кигән сакчылар күрә һәм көче бетеп, тынып кала. Тик шунда гына ул үзенең авыр хәлен аңлый һәм ирекне өзелеп сагына башлый.

Миша һаман йоклый әле. Мин аның янында утырам. Башымнан нинди генә уйлар узмый. Инде нишләргә? Кинәт һавада самолёт очкан тавыш ишетелә. Кемнеке? Барыбыз да тынып тыңлыйбыз.

– Безнеке! – ди берәү.

– Немецларга бүләк китергән…

Кайдадыр бомба шартлаган тавыш ишетелә. Шушы бер шартлау да күңелдә ниндидер ышаныч уята: фронт якын бит әле.

– Их, – ди берәү, – иртә белән безнекеләр Оршага бәреп керсәләр, булыр иде кызык!

– Бездә әллә самолётлар юкмы? – ди икенче иптәшебез. – Тотты да төшерде десант, шуннан эше бетә фрицның, капут! Безнекеләр белән не шути…

Күңелдә өмет чаткысы кабынып куя. Шул сүзләргә чын йөрәктән ышанасы килә. Бер генә минутка булса да уйлар яктырып китә.

Төн һаман караңгылана бара. Ишегалдында кемнәрдер учак кабызырга маташалар. Шырпы яктысы күренү белән, капка янындагы пулемёт тырылдап куя. Шунда кемдер кычкырып егыла, һәм тавыш тынып кала. Кемдер, рус телен ватасындыра:

– Ут яндырырга ярамый! – дип җикеренә.

Сакчылар мылтык затворларын шалтыратып куялар.

Прожектор уты тагын сузылып ала һәм сүнә.

Безнең бүлмәдә тынлык. Әсирләр икешәр, өчәр булып бер-берсенә елышып ятканнар. Тик берәү дә йокламый. Һәркемнең башында «Нишләргә?» дигән уй кайный.

Мин Миша янында ятам. Минем дә, Миша кебек, йокыга таласым килә. Юк, булмый, тагын торып утырам, уйлыйм: «Нишләргә?» Качарга кирәк, качарга! Ә ничек качарга соң? Уйлыйм, тагын уйлыйм.

Мин үземә үзем җавап таба алмыйм. Чигә тамырларым авырта, тешләр кысыла. Шушы караңгы бүлмәдә мин үземне төпсез коега төшеп барган кебек сизәм. Мин әле моннан берничә сәгать кенә элек ирек турында үзем генә уйларга һәм үзем теләгәнчә юлын табарга хаклы идем. Ә хәзер минем иптәшем, якташым бар. Ул яралы. Качарга мөмкин булса да, яралы иптәшемне ташлап китәргә ярыймы соң?

Кинәт тышта, гөрелдәп, машина килеп туктады. Немецлар, сөйләшә-сөйләшә, йортка керделәр. Безнең ишек төбенә таба адымнар якынлаша. Менә ишек ачылды. Бүлмәдә кесә фонареның яктысы йөри башлады. Яктылык кайбер солдатларның йөзләренә озак тукталып торды.

Немецлар керү белән, бүлмәгә ислемай исе таралды. Ә соңрак без спирт исен дә сизә башладык. Димәк, алар салганнар иде. Караңгыда без аларның йөзләрен күрмәсәк тә, керүчеләрнең офицер булуларына шигебез калмады.

Бу төн уртасында нишләп йөри алар? Бүлмәдә тынлык. Офицер кесә фонаре яктысын бер солдаттан икенче солдат йөзенә йөртеп уза. Кемнедер эзлиләр.

Кинәт бүлмәдә, шул авыр тынлыкта, офицерның тавышы ишетелде. Гадәттә, тавышның төсе юк, диләр. Ләкин ни өчендер бу вакытта миңа немец офицерының тавышы зәңгәрле-яшелле төстә булып тоелды. Офицер немец телендә нәрсәдер әйтте. Без бары «коммунист» дигән сүзне генә аңлап калдык.

Без барыбыз да аягүрә торып бастык. Бу коралсызланган солдатларның, иңне иңгә куеп, терсәкне терсәккә терәп, дошманга каршы чыгуы иде.

Офицер җавап көтте. Без эндәшмәдек.

– Йә, әйтегез, – диде ул, – кем биредә коммунист, кем комиссар?

Бүлмә һаман тып-тын торды.

– Димәк, барыгыз да коммунистлар, – диде немец ачулы тавыш белән. – Ярый, бик яхшы. Ләкин белегез: барыбер әйтерсез. Бүген түгел икән, иртәгә, иртәгә түгел икән, аннан ары. Безнең вакыт бар, без көтә алабыз, – диде дә офицер, иптәшенә нәрсәдер сөйли-сөйли, бүлмәдән чыкты. Ишек ябылды, шалтыр-шолтыр иткән тавышлар ишетелеп калды.

– Менә болары инде чын фашистлар, – диде кемдер бер почмактан.

Бу сүз караңгы бүлмәдә коточкыч булып яңгырады. Ниндидер бер очлы нәрсә күзләрне чәнчеп киткәндәй булды. Ул сүз йөрәкләрне дерелдәтеп алды. Йоклап яткан, дөресрәге, аңын җуеп яткан Миша да урыныннан сикереп торды һәм: «Ах!» – дип, яралы иңбашын тотып, таш идәнгә ауды.

Әйе, фашистлар! Без аларны сугышка кадәр үк белә идек. Фашистларның Испаниядә, Австриядә, Польшада бер гаепсез халыкны үтерүләре турында газеталардан, журналлардан укыганыбыз бар иде. Ә менә бүген без фашист белән йөзгә-йөз килеп, күзгә-күз карашып очраштык.

– Болары инде чын фашистлар, – дип кабатлады баягы тавыш. Мин аны күрергә теләдем. Бүлмә караңгы, беркемне дә танып булмый. Бәхеткә, ул солдат тәмәке кабызды, һәм шул арада мин аның йөзен күреп калдым. Ул урта яшьләрдәге кеше иде. Шактый киң маңгае, туры борыны һәм шырпы яктысында ниндидер бер әчке көч белән ялтыраган күзләре минем күңелемә кереп калды. Шырпы сүнгәч тә, ул күзләр һаман янып торалар иде кебек.

Нәби ДӘҮЛИ



ИЗГЕ ӘМАНӘТ

Каюм Насыйри музеена 25 ел



Дөньяның бик матур бер көне иде. 1982 елның декабрь ае. Тарихи көнкүреш әйберләрен җыярга туган авылым Олы Ачасырга кайттым.

Ни хәл итәсең, табигатьнең үз көе булган кебек, җәмгыятьнең дә үз кануннары бар. Безнең илдә декабрь ае урак өсте: эшләп бетерелмәгән эшләр эшләнә, еллык планнар тутырыла һәм, ниһаять, айның егермеләреннән соң, гадәттә, ел буе көткән акча бирелә. Бу очракта – экспедициягә дип әйтүем.

Экспедициядә бик күп кызык әйбер таптым. Безнең авыл кадими, дини, буларак дөнья вәзгыяте алдында «кара» булып денсез цивилизациягә каршы тора алырлык итеп сакланып кала белгән иде әле ул вакыт. Өйләрнең күбесендә иске әйберләрнең кадере беленә иде.

Мәктәптә укыганда ун ел буе, «Каюм Насыйри йорты»дип йөрелә торган бер бик матур өйне узып йөргән идем. Башка йортлардан ул чатыр түбәле булуы, ишегалды таштан, киң, иркен булуы белән аерыла иде. Монда гомер буе авылда торып тимер юлда эшләгән, кеше арасында тырыш, үҗәт, тәкъва булуы белән даны чыккан Габделгани абый Минзарипов тора иде. Карчыгы Хәбирә апаны, елы тулганчы, нигезендә искә алып дога кылу өчен, балаларына күчеп китмәгән. Габделгани абый мине – авылдашы Әсрареддин кызын бик мөлаем, безнең авылча кубарылып купмый, гади генә каршы алды.

«Нишләп бу йортны Каюм Насыйри йорты диләр?» – дип сорагач: «Әйдә кызым, туңганчы өйгә кер, аннан күрерсең», – диде.

Башта мине болдыр ишегендәге бөгәҗәле тимер тотка җәлеп итте. Ул уң кул уңаена ике яклап ачыла торган төрле буйдагы кешегә уңай итеп урнаштырылган.

Чоланда өч ишек: берсе кәҗәнкәгә керә торганы – бу исем каян алынгандыр мәгълүм түгел. Хәзер бу җирне веранда дип атыйлар. Анда кечкенә өстәл, урындык куелып, тәрәзәсе бакчага карый. Гадәттә кәҗәнкәдә сандыклар, кунаклар килгәндә кирәк була торган савыт-саба, урын-җир саклана. Күп кешенең чормага менә торган баскычы да кәҗәнкәдән менеп китә.

Акрын гына ачып, уң яктан бозау тиресе белән тышланган ишектән түр якка уздык.

Кайвакыт кешегә ни йомыш белән кергәнлегең онытыла. Хәл-әхвәл сорашыла, ике яклап изге теләкләр теләнелә. Шуннан соң гына искә килеп, төп йомышка күчелә. Җылы мич янында чәй гел җылы торганга хуҗа самавырга йә чәйнеккә ябышып, кергән кешенең йомышын тыңлый, кыстый-кыстый берәр чынаяк чәй эчкәндә, гозерләр сөйләшенә…

Бу чак алай булмады. Доганы Габделгани абый эчтән үзе генә кылгандыр. Мин өй уртасында шаккатып басып калдым.

Үзәктә – таяклары сырлап эшләнгән зур түгәрәк имән өстәл. Өстәлнең ике канаты аска төшеп кечерәк овалга әйләнә ала. Урындыкларга күмер самавырлары тезелгән. Алар матур итеп, ап-ак, кулдан бәйләнгән түгәрәк челтәрләр белән капланган. Стеналарда өч-дүрт данә торган сәгатьләр, шәмаилләр. Почмакны (кухня ягы) түр яктан аерып торган ап-ак зур мичнең төнлекләре гадәттәгечә кирпеч түгел, ә матур түгәрәк металл капкачлар белән бизәлгән. Мич кашларында (кучкар) төрле зурлыктагы керосин лампалар, шәмдәлләр. Йортның тәрәзәләре гадәттәгедән бераз зуррак, түшәм дә биегрәк тоелды.

«Минем, кызым, бер әманәтем бар, кер әле монда», – дип Габделгани абый мине почмакка чакырып кертте, андагы тәбәнәк сәкегә утыргач: «Мин бу йортны сугыштан кайткач, өйләнеп башка чыгу өчен Шырданнан алып кайттым. Аны миңа Каюм Насыйриның туганының килене сатты, исеме онытылган. Шуннан кайткан дүрт әйберне: стена көзгесе, савыт-саба шкафы, кәҗәнкәдәге кәнәфи һәм менә бу сәкене Каюм Насыйри үзе ясаган диделәр. Сәкедә ул йоклап йөргән». Хуҗалыкта җәйсызрак булса да, истәлекле сәкене Габделгани абый кулланыштан төшермәгән. Гомер буе мич каршында карчыгы Хәбирә апа шул сәкедә бәлеш ясаган.

Әманәткә тугры булып, аны җиткерә белү безнең якта мөселманлыкның иң әһәмиятле шартларыннан исәпләнә.

Гасырлардан килгән тарихи риваятьләр, буыннан-буынга килгән гыйлем, тәҗрибә дә, хәтта берничә минуттан җиткерелү өчен әйтеп җибәрелгән сәлам дә – мөэмин бәндә өчен, һичшиксез, үтәлергә тиешле изге әманәт санала.

Габделгани абый йортның бу ягындагы (Шырданнан кайткан) астан дүртәр бүрәнәне алмаштырып, ә арт яктагы кечкенә бүлмәсен бөтенләй яңадан салганын әйтте. Кече бүлмәдә гадәттәгечә хәзерге заман җиһазлары: өстәл, урындыклар – ашау-эчү өчен җайланган. Бу бүлмәдә дә мич, аның алдында буеннан-буена сузып эшләнгән уңайлы чын сәке. Мич янында сәндерә: үсмер балалар йоклау өчен ясалган мич башыннан биегрәк югары сәке. Сәндерә өсте һәм бүлемдәге ишек уемнары чаршау-кашагалар белән капланган иде.

Музей кешесе өчен иң кызык җир – чорма. Анда вакыт сынавын узып тарихка күчеп килә торган әйберләр саклана. Габделгани абыйдан сорап, мин дә чормага мендем. Үзе аста калып, аңлатып торды. Монда моңарчы авылда гына түгел, Россиянең иң борынгы музейларыннан саналган дәүләт музее фондларында булмаган һәм мин исемнәрен дә белмәгән әллә нинди кызык әйберләр тулып ята. Алар матур итеп төрле сандык, кәрҗиннәргә таслап тутырып куелган: ашлык саклый торган 80-100 см биеклектәге зур чүлмәкләр, авыл хуҗалыгы кирәк-яраклары, кием-салым.

Каралты-кура, бакча, мунча тирәләрен карап чыккач, Габделгани абыйдан «Ә без монда музей ясасак, йортыңны сатырсыңмы?» – дигәч, ул: «Ал да яса, кызым, акча кирәкми, бер генә шартым бар – аракы эчкән кеше генә тормасын. Нигезендә черсә дә, ризамын», – диде.

Авылда җыелган әйберне апам Асиянең ире – Кыртапа егете Рифат җизни машинасына төяп музейга, Казанга кайттып киттем. Бу йорттан музей ясый калсак, үз әйберләре үзендә булсын дип, бер әйбер дә алмадым.

Казанда бу хәлне тарихи ядкәрләр саклау оешмасы башлыгы, университетның тарих-филология факультетыннан сабакташым Рафаэль Вәлиевкә сөйләгәч, ул барып карады. XIX гасыр утарлары арасында тарихи яктан дөрес сакланып калганнары бик сирәк. Шундый риваятьле бүләкне ничек булса да саклау һәм музей рәвешенә китерүне ул да үзенә әманәт итеп кабул итте.

Туксанынчы елларда башланган акчасызлык һәм бик күп башка объектив һәм субъектив каршылыкларга карамыйча, 1997 елның беренче мартында «Каюм Насыйри исемендәге архитектура һәм этнография музей-утары» дип, Габделгани абый белән Хәбирә апа йортының кунакчыл ишекләре ачылды. Минем күңел төшкән вакытларда әнкәйнең: «Шуның кадәр дубра (добро) алып калып, Габделгани абый әманәтен ташласаң, Аллаһ каршында ничек җавап бирерсең?» – диюе исән вакыт өндә, китеп баргач – төштә гел искә төшереп, нык булырга өндәп торды.

Рәмзия АБЗАЛИНА.





Тынычлык алып

Без илаһи кануннар идарә иткән гаҗәеп дөньяда яшибез. Сәламәтлек, мәхәббәт, уңыш – болар барысы да әлеге кануннарга бәйле. Әмма күп нәрсә үзебездән дә тора! Шунлыктан Яңа елны ничек каршы алсаң, ел шулай үтәр, дигән сынамышка да күбебез ышана. Киләсе ел нинди булыр икән, аны ничек каршыларга кирәк – шул хакта сөйләшик.

Әллә Куян, әллә Мәче елы...

Кытай календаре буенча 2023 ел – кара су Куяны елы, тик әле аны Мәче елы дип атаучылар да бар. Ул 22 гыйнварда башланачак. Шәрык йолдызнамәсе бер генә төгел, аларда хайваннар да төрле: Кытай зодиагында дүртенче булып – Куян, Вьетнам, Япония, Таиландныкында исә Мәче килә. Россиядә исә баш ватып азапланырга кирәкми: тегесе дә, бусы да ел хуҗасы санала ала. Алар икесе дә – йомшак, наз яратучан хайван, шунлыктан яңа ел да шундый ук тыныч, мәрхәмәтле булыр, гаилә бәхете алып килер, дип көтелә. 2023 ел – Ай циклының дүртенче елы, тагын шунлыктан да кытайлар аны бик бәхетле булачак, дип юрый.

Яңа елдан нәрсә көтәргә?

Яңа ел беренче карашка гына чагыштырмача тыныч булыр кебек, әмма ул көтелмәгән борылышларга да бай булачак. Уңышка ирешер һәм хаталар җибәрмәс өчен, бу елда бик кирәкле файдалы сыйфатлар хакында истән чыгармау зарур: фикерләү зирәклеге; килеп туган хәлгә яраклаша алу сәләте; усалланмау; проблемаларны тыныч юл белән хәл итә белү осталыгы. 2023 елны гаиләгә багышларга, яраткан кешеләр һәм балалар турында кайгыртырга, аларны гел сөендерергә кирәк. Ялгызларның үз парын табу ихтималы зур. Байлыкны арттыру өчен күп тырышу, акыл белән эш итү, яңа белем үзләштерү таләп ителәчәк, эш урынын алыштырмый тору мәслихәт. Сәламәтлеккә килгәндә, Куян (Мәче) елында аеруча сулыш әгъзалары һәм бөер зәгыйфь, аларны саклау мөһим. Хатын-кыз энергиясе елы булганга, барлык гүзәл затларга үз сәламәтлеген кайгырту зарур. Бу елда алкоголь куллану организм өчен бигрәк тә зарарлы, шунлыктан әлеге начар гадәттән бөтенләй бизү яхшы. Ә менә спорт белән шөгыльләнү бары тик файда гына китерәчәк.

Карамы, кызылмы?

Безнең кәефебез кигән киемебезнең төсенә, стиленә бәйле рәвештә үзгәрергә мөмкин. Астрологлар фикеренчә, Яңа елны каршылаганда киемне бик җентекләп сайлау зарур. Кара Куян елын кара, ак, соры, зәңгәр, яшел төс өстенлек иткән киемдә каршылау яхшы булыр. Модельерлар исә куе кызыл (Viva Magenta) төсмерен 2023 елның төп төсе дип игълан итте, шунлыктан мондый төстәге киемнән каршылау да актуаль. Артык кыйммәтле киемнәр кирәкмәс. Бәрхет күлмәк, челтәрле ап-ак блуза, тафта итәк, агач һәм таш аксессуарлар аеруча хуплана. Йә алтын гына, йә көмеш кенә бизәнү әйберләрен тагу хәерле. Табигый материаллардан ясалган бизәнгечләр исә теләсә нинди киемгә килешә.

СӘЛАМӘТЛЕК ЙОЛДЫЗНАМӘСЕ-2023

КҮСЕ

(1936, 1948, 1960, 1972, 1984, 1996, 2008, 2020)

КҮСЕ елында туучыларның сәламәтлеге зарланырлык түгел. Дөрес, аларның организмы әледән-әле ярдәмгә мохтаҗ булачак, тик моның сәбәбе тулаем физик халәтнең начарлыгында түгел, бәлки сәламәтлекне кайгыртуга бөтенләй игътибар бирмәүдә. Күсе, нәрсә белән дә булса бик каты мавыкса, дөньясын онытa, хәленең начарлануына җитди карамый. Әйе, физиология ягыннан тайпылышлар тиз арада үтеп китәрлек кенә булачак, ә менә нерв системасына зур зыян киләчәк. Шунлыктан Күсегә нервларын ел дәвамында кайгырту мөһим. Психологик сәламәтлекне саклау һәм ныгыту өчен, даими рәвештә витаминнар эчү, төрле релакс процедуралары үткәрү мәслихәт.



КУЯН

(1939, 1951, 1963, 1975, 1987, 1999, 2011)

КУЯН елында туучыларның физик сәламәтлегенә бернинди куркыныч та янамый, ә менә психологик халәте бераз борчу тудырырга мөмкин. Моңа гаҗәпләнергә дә, әллә ни хафаланырга да кирәкми. Ел буена артык дулкынланмый-ярсымый яшәргә тырышу мәслихәт, нинди дә булса гайре табигый (экзотик, көчле тәэсирле) чараларны куллану катгый тыела.



ҮГЕЗ

(1937, 1949, 1961, 1973, 1985, 1997, 2009)

ҮГЕЗ елында туучыларның сәламәтлеге яхшы, аларның организмы һәртөрле чирләргә каршы торырлык нык. Бары тик көнкүрештә сак булу сорала, чөнки егылуимгәнү ихтималы зур. Шунлыктан ел буена бик игътибарлы булырга, ашыкмаска-кабаланмаска киңәш ителә.

АҖДАҺА

(1940, 1952, 1964, 1976, 1988, 2000, 2012)

АҖДАҺА елында туучыларның күпчелегенең сәламәтлеге яхшы. Кайбер хилафлыклар исә озакка сузылган проблемалар китереп чыгармас – яшәү рәвешен үзгәртүне, саулыкны кайгыртырга күп акча түгүне таләп итмәс. Бердәнбер игътибар бирәсе урын – ашкайнату системасы эшендә тайпылышлар пәйда булу. Шунлыктан ел башыннан ук вакытында һәм дөрес тукланугa күчү мәслихәт, башка борчылыр әйбер юк.

ЮЛБАРЫС

(1938, 1950, 1962, 1974, 1986, 1998, 2010)

ЮЛБАРЫС елында туучыларга сәламәтлекләре турында әллә ни кайгыртырга туры килмәячәк. Дөрес, ул ел буена гел идеаль да булмаячак әлбәттә, шулай да артык хафаланырлык чирләр көтелми. Ике төрле куркыныч янавы мөмкин: беренчесе – аллергия, икенчесе – көнкүрештә имгәнү. Аллергиядән саклану өчен алдан ук профилактика чараларын күрү мөһим, ә бәрелмәсегылмас өчен даими игътибарлы булу сорала.



ЕЛАН

(1941, 1953, 1965, 1977, 1989, 2001, 2013)

ЕЛАН елында туучыларның сәламәтлеге зарланырлык түгел, ара-тирә вак-төяк һәм тиз үтеп китә торган чирләр генә борчып алгаларга мөмкин. Шулай ук кайвакыт бавыр һәм эчәклек эшендә тайпылышлар килеп чыгуы ихтимал, тик моны җайга салу бик җиңел – бары тик дөрес тукланырга гына кирәк.

Куян һәм мәче турында мәкальләр

Бер елга куян тиресе дә чыдаган.
Биш тиенлек куян, ун тиенлек зыян.
Ике куян куссаң, берсен дә тотмассың.
Куян үз куләгәсеннән дә куркыр.
Куян тауга үкләгән, тауның исендә дә юк.
Шашынган куян аучы өстенә сикерер.
Өркетмә куянны, арыслан итәрсең.
Мышытым мәче майны күбрәк ашый.
Мәче тырнагында сандугач сайрамас.
Мәче урлар, эт түләр.
Мәчене түбәдән атсаң да, дүрт аягы өстенә төшәр.
Сыйпаганны песи дә ярата.

Кил, йомшаккай!

АТ

(1942, 1954, 1966, 1978, 1990, 2002, 2014)

АТ елында туучыларга сәламәтлекләрен бераз кайгырту зарур. Беренче чиратта йөрәк, бавырга һәм кан күрсәткечләренә игътибарлы булу сорала. Билгеле, килеп чыккан һәр чир нәкъ шуларга бәйле булачак, дигән сүз түгел, әмма шулай да ел буе аларның халәтен тикшертеп тору зарар итмәс. Икенче зәгыйфь урын – зарарлы гадәтләр, бу елда аларның аеруча зыяннылыларыннан котылу җиңел биреләчәк.

ӘТӘЧ

(1945, 1957, 1969, 1981, 1993, 2005, 2017)

ӘТӘЧ елында туучыларга сәламәтлекләрен кайгырту зарур. Аларга үз бәдәннәренең көч-куәтенә генә өметләнү җитәрлек булмаячак. Ә инде организмга бераз ярдәм итеп, тикшеренеп һәм вакытында дәваланып торганда, ел шактый тыныч үтәр. Үт куыгы, эчәклек эшен контрольдә тоту мөһим. Нерв системасын саклау мәслихәт – бер сәбәпсез кәеф төшсә, нык ардырса, артык каты тәэсирләндерсә, шундук тынычланырга тырышу хәерле.

САРЫК (КӘҖӘ)



(1943, 1955, 1967, 1979, 1991, 2003, 2015)

КӘҖӘ (Сарык) елында туучыларның сәламәтлеге зарланырлык булмаячак. Алдагы 12 айны чир-борчуларсыз үткәрү өчен, организмны аз гына кайгырту да җитә. Күпчелек шулай эшләячәк тә, әмма кайберәүләр бик ваемсызланып, сәламәтлек куәтен тиз арада исраф итеп ташларга мөмкин, шуннан соң исә аларның организмы хәлсезләнәчәк. Болай килеп чыкмасын өчен, әллә ни тырышлык та кирәкми үзе – физик хезмәттә дә, ашау-эчүдә дә чама хисен генә югалтмау мөһим.

ЭТ

(1946, 1958, 1970, 1982, 1994, 2006, 2018)

ЭТ елында туучыларның сәламәтлеге зарланырлык түгел. Ашкайнату системасы эшендә генә хилафлыклар килеп чыгарга мөмкин. Шунлыктан туклану рационын үзгәртү, ашау режимын тәртипкә китерү зарур. Тик бу бик җиңел булыр, дип уйламагыз. Шактый кыенга туры киләчәк – чөнки кайбер ризыклардан бөтенләй баш тарту таләп ителә. Ел башыннан ук дөрес тукланганда, саулык сөенерлек булачак.

МАЙМЫЛ



(1944, 1956, 1968, 1980, 1992, 2004, 2016)

МАЙМЫЛ елында туучылар үзләренең сәламәтлеге турында ел башыннан ук кайгыртырга, кирәкле тикшеренүләрне вакытында үтәргә тиеш. Ваемсызланып йөрмәү хәерле. Сәламәт яшәү рәвеше алып бару зарур – вакытында йокларга, дөрес тукланырга, саф һавада күбрәк булырга, стресслардан сакланырга кирәк.

ДУҢГЫЗ (КАБАН)



(1947, 1959, 1971, 1983, 1995, 2007, 2019)

ДУҢГЫЗ елында туучыларның сәламәтлеге шәп булачак, шунлыктан хәтта зарарлы гадәтләре дә организмнарына әллә ни зыян китермәячәк. Әмма бу елда гына түгел, киләчәктә дә саулык куандырырлык булсын өчен, сәламәт яшәү рәвеше алып бару һәм зыянлы гадәтләрдән арыну хуплана.

Табын күрке – яшелчә һәм сыр

Бәйрәм табынын мул итеп әзерләргә тырышыгыз. Салатлар, яшелчә-җиләк-җимеш, укроп-петрушка-кинза өстенлек итсен. Кыяклы үсемлекләрдән әзерләнгән нигъмәтләр, сөт ризыклары, бигрәк тә сырның күп төрлесен кую яхшы. Иттән сый-хөрмәт бөтенләй әзерләмәү хәерле. Ә менә кош ите, балык күп булса яхшы. Табын әзерләгәндә ашыгырга ярамый. Ашамлыкларның төре азрак, күләме күп булсын. Ризык никадәр гади булса, шулкадәр яхшырак. Куянның (Мәченең) күңелен күрү өчен, баллы тәм-томнан өстәл сыгылып торсын, торт, чизкейк һәм туңдырма теләсә кемнең күңеленә хуш килерлек булсын. Яңа ел табынында туйганчы сыйлану мәслихәт. Ә менә исерткеч эчемлекләрнең бөтенләй булмавы ел хуҗаларына аеруча ошаячак – әлеге хайваннар аек акыллыларны ярата. Җитен эскәтер, агач тәлинкәләр, бәллүр савытлар, хуш исле шәмнәр, нарат-чыршы күркәсе һәм җиләк-җимешләрдән ясалган композицияләр бәйрәм табынын тагын да күркәмләтә төшәр.

Бүләк сайлыйбыз

2023 елга иң шәп бүләк – үзара уңай мөнәсәбәтләр. Бүләкнең бәясе мөһим түгел, ул үз кулың белән ясалган яки якыннарыңның зәвыгын яхшы белеп сайланган булырга тиеш. Җылы плед, кул эшләре өчен җыелма, матур сервиз, йомшак оеклар яки фитнес-клубка еллык абонемент белән сөендерергә була. Төп бүләккә куян яки мәче сыннары яки алар сурәтләнгән чыршы уенчыклары өстәргә онытмаска гына кирәк.

Төкле тәпиең белән!

Куянның да, Мәченең дә күңеле киң, алар юмарт һәм кызганучан. Шунлыктан Яңа ел бәйрәмнәрендә кем турында булса да кайгырту бик мөһим. Ярдәмгә мохтаҗларга булышыгыз. Бала-чаганы мандарин-шоколад белән сыйлагыз, өлкәнрәк яшьтәге күршеләрегезне кечкенә генә булса да бүләк биреп сөендерегез. Әйләнә-тирәдәгеләргә мәрхәмәтле булган очракта гына киләсе ел уңыш китерәчәк. Яңа елга кергәндә өйне җыештыру, тәрәзәләрне һәм пәрдәләрне юу, кирәкмәгән әйберләрне чыгарып ташлау турында да онытмау зарур.

Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Мәдәни җомга
30 декабрь
№51, 2022

УРТАК ТӨРКИ ТАРИХ



● Шаһ Аббас II.

Алтын Урдадан бүленеп чыккан ханлыкларның җимерелүе – бөтен төрки дөньясы язмышында тирән эз калдырган борылыш моменты. Бу – күп гасырлык колониаль сәясәтнең төрки халыкларга карата даими рәвештә алып барылган башлангыч һәм үзәк темалары. Әстерхан һәм Казан ханлыкларын оккупациядән коткаруның көрше һәм кардәш ханлыклар тышкы сәясәтендә озак вакытлар өстенлекле юнәлеш булып калуы очраклы түгел.

Әстерханны яулап алганнан соң, патша хакимиятенең һаман үҗәтләнеп Кавказга үтеп керү максаты Госманлы дәүләтен актив рәвештә кысылырга мәҗбүр итә. 1569 елгы атаклы Әстерхан походы – Госманлы дәүләтенең азат итү миссиясенең ачык мисалы. Дон һәм Идел елгалары арасында канал салу һәм Каспий диңгезен Кара диңгез белән кушуда баш вәзир, полководчы Сокуллу Мәхмүт-пашаның төп максаты Түбән Идел бассейныннан русларны куып җибәрү, һәм шулай итеп, Төньяк Кавказның куркынычсызлыгын тәэмин итү була. Мәхмүт паша, шулай ук, Сефевидлар хакимияте белән сугышта дошманының тылына һөҗүм ясау, Госманлы дәүләте һәм аның белән союздаш булган Төркестан ханлыклары белән ике арада элемтә урнаштыру максатларын да күз алдында тота. Күргәнебезчә, саналган бу факторлар гомумтөрки тарихта мөһим эпизодлар булып тора һәм үзара тыгыз бәйләнештә өйрәнелергә тиеш. Аларны бер-берләреннән аеру һәм индивидуаль рәвештә өйрәнү – үзеңне алдан ук уңышсызлыкка дучар итү ул. Зур кызыксыну тудырган сорауларның берсе – Алтын Урда җирләре өчен көрәшнең хәтта XVIII гасырда да дәвам итүе. Бөек полководчы Надир-шаһ Афшарның, Дагыстанны тәмам буйсындыргач, 1742 елда Әстерханга поход белән барырга җыенганлыгы билгеле.

Без үзебезне историограф дип түгел, гап-гади публицист дип саныйбыз һәм үзебезнең «алар җирендә» хәбәрдар булмавыбыз һәм наданлыгыбызны алдан ук таныйбыз. Без төрки халыкларны «культуралы басып алу» темасын сәяси оккупациягә карашны тоташ үзгәртүче буларак өйрәнергә; көчләү процессларына хас үзенчәлекләрне (христианлаштыру, руслаштыру, халыкларны күчерү сәясәте һ.б.) ачыкларга, аларның сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен анализларга омтылабыз. Бу тема сәяси басып алу белән аерылгысыз бәйләнгән, шуңа күрә без тарихи вакыйгалар барышын тирәннән белергә тиеш. Әмма басып алу процессларын өйрәнгәндә, беренче караштан ук, җәмгыять тәртибендә мөһим регулятор булып торган хакимиятнең төрки этикеты, тел, шәригать нормаларының вакыйгаларга тәэсире һәм роле турындагы әһәмиятле сорауларның читтә калганын күрәбез.

Басып алу феномены үзе дә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Билгеле, оккупация иң гуманлы чагылышында да көчләү акты булып кала, һәм бу көч куллану – территория һәм халык өстеннән контрольнең басып алучылар кулына күчүе; идарә итү, законлылык, социаль иерархия стиле һәм мөнәсәбәтләрнең тотрыклы системасы үзгәрү белән генә чикләнми. Ул социаль эшчәнлекнең тирән катламнарына үтеп керергә, чикләрне киңәйтергә, иҗтимагый һәм шәхси тормышта, көнкүрештә, хисләр, уйлар һәм кешеләрнең ышануларында өстенлек итәргә омтыла.

Тарих ул – вакыйгалар арасында сәбәпнәтиҗә бәйләнешен ачу һәм эзлеклелекне табу. Моңа мисал итеп, Азәрбайҗан тарихы белән тыгыз бәйләнгән бер фактны ачыклау һәм күрсәтү дә җитә.

Югарыда әйтелгәнчә, Әстерханны алганнан соң, патша хөкүмәте Кавказга юл сала, һәм Сунҗа елгасы Терекка коя торган урында Тарка дип аталган ныгытма төзелә (1567). Госманлы дәүләтенең Әстерханга походында бу ныгытма җимерелүгә карамастан, Иван IVнең Каспий буе территорияләре белән кызыксынуы кимеми. Россиянең Казан һәм Әстерхан җирләрен басып алуын куәт-көч билгесе дип санаган Сефевидлар дәүләте бу кызыксынуны госманлыларга каршы көрәштә үз файдасына юнәлтергә тырыша. Шаһ Тахмасиб I рус патшасын союздаш дип таный, Госман-Сефевид сугышында төньяктан – Дагыстан һәм Дербент аша Азәрбайҗан җирләренә даими бәреп керүче Кырым татарларына комачаулый алыр иде дип саный. 1553 елда (Казанны алу тулысынча тәмамланмаган әле!) ул Мәскәүгә үзенең илчесе Сәет Хөсәенне сөйләшүләр өчен җибәрә. 1561 елда Иван IV сараенда тагын бер сефевид илчелеге булуы да билгеле.

1569 елда Сәлим солтан гаскәрләре Әстерханга бәреп кергәч, Тахмасиб I янә илчесен җибәрә һәм патшага союз тәкъдим итә, ә Иван IV Казвин шәһәренә сарай түрәсе Алексей Хозниковны җитәкчелегендә җавап илчелеген җибәрә. Күп кенә чыганакларда, «яхшы ният» чагылышы буларак, Хозниковның Сефевидлар сараена 100 пушка һәм 500 винтовка алып килгәнлеге хәбәр ителә. Сөйләшүләрдә госманлыларга каршы бердәм фронт ачу турында фикер алышканлыклары – исбатланган факт. Бу чорда Якын һәм Урта Көнчыгыш базарларына омтылган һәм Тахмасиб I белән сәүдә элемтәләрен ныгытуга аерым игътибар биргән Иван IV Сефевид – Госманлы каршылыгын тагын да ныграк котырта, шулай итеп, ике мөселман дәүләтен дә зәгыйфьләндерә, аларның үзара дошманлыгыннан файдалана һәм, әкренләп, Каспийга таба хәрәкәт итә. Нәкъ менә шуңа күрә 1578 елда Госманлы дәүләтен Кавказга күчерү уе, чынбарлыкта, Россиянең Каспий диңгезе төбәгенә походларына юл куймау максатыннан булган, дигән фикергә җитди нигезе бар. 1580 елда Тарка (Терек) ныгытмасын торгызу, яңа ныгытмалар төзү һәм якын-тирә территорияләрдә казаклар урнаштыру, ә 1587 елда Картли-Кахетияне Россия канаты астына кабул итү рус патшасының тәвәккәллеген күрсәтә. Госманлы дәүләте бу киңәюләргә төрле юллар белән каршы торырга тырыша. 1590 елда Сараб шәһәрендә сефевидлар белән имзаланган тынычлык килешүе бу версияне раслый. Төркия тарихчысы Наима сүзләренә караганда, Госманлы сараеның катгый таләбе буенча, бу килешүгә Сефевидлар ягы рус ныгытмасы Тарканы җимерү турында солтан указын тормышка ашыруда комачауламаска тиеш, дигән шарт кертелә.

Шуны да таныырга кирәк: Сефевидлар тарихы, шул исәптән Россия – Сефевидлар мөнәсәбәтләре үсеше, Азәрбайҗан тарихында һәрьяклап өйрәнелгән мәсьәлә. Ләкин Азәрбайҗан – Россия мөнәсәбәтләре турында узган гасырның 60нчы елларында ук Әхмәт Хөсәеновның эшендә чагылыш тапкан, әмма соңрак тарихчылар аны игътибарсыз калдырган яки өстән-өстән генә шәрехләгән бер факт бар. Гәрчә ул патша хакимиятенең Кавказ сәясәтен дөрес бәяләү, аның үсеш этапларын билгеләү һәм ачыклау ягыннан гаҗәеп әһәмияткә ия.

Без бу факт белән беренче тапкыр төрек тарихчысы Җихат Айдогмуш оглуның Сефевидлар тарихына багышланган хезмәтендә очраштык. Ул болай дип яза: «Шаһ Аббас хакимияткә килгәннән соң, озак та үтмәстән, Иранга рус илчесе Васильчиков җибәрелә, ул 1589 елның 9 апрелендә патша сараенда кабул ителә. Ул шаһка бүләкләр һәм патшадан хат алып килә. Хәтта рус патшасы ике ил арасындагы дуслыкны ныгыту өчен аңа моңа кадәр шаһ Мөхәммәд Ходабәндә тарафыннан вәгъдә ителгән Дербент һәм Бакуны сорый. Шаһ Аббас ике илнең дуслыгы хакына бу ике шәһәрнең рус патшасына бүләк ителәчәген әйтә. Баку һәм Дербент ул вакытта госманлылар кулында була. Шаһ Аббас, рус илчесенә үз иленә кайтырга рөхсәт биреп, аның белән бергә үз илчеләре Хаҗи бәй һәм Будаг бәкне җибәрә. Бу делегация 1590 елның маенда Кремльдә кабул ителә. Шаһ Аббас хатында, ике дәүләткә дә Госманлы дәүләте аркасында өзелгән элемтәләрне торгызырга, үзара дуслыкка нигезләнгән мөнәсәбәтләрне җайга салырга кирәк, дип яза һәм Баку һәм Дербентны үзенең «патша кардәшенә» бүләк итүен билгеләп үтә.

Һади һәм Будаг бәйләрнең илчелек миссиясе турында Азәрбайҗан тарихчылары да сөйли. Низами Сөләйманов сефевидлар турындагы китабында, шаһ Аббас аларга Россия белән хәрби союз турындагы сорауны яңадан күтәрергә куша һәм илчеләр патшадан хәрби ярдәм сорый, ләкин уңышка ирешә алмый, дип яза. Ләкин, автор Баку һәм Дербент турында искә алмый. 1994 елда вузлар өчен дәреслек сыйфатында бастырылган «Азәрбайҗан тарихы (борынгы заманнардан XX гасырга кадәр)» китабында болай диелә: «XVI гасырның соңгы чирегендә Сефевид дәүләте өчен дә халыкара хәл начар якка үзгәрде... Бары тик төньяк көрше – Россия белән генә мөнәсәбәтләр җайга салынды. Әмма Баку һәм Дербентны тапшыру хисабына госманлыларга каршы руслар белән союзга керү тәкъдиме нәтиҗәсез калды». Бер яктан, «нәтиҗәсез калды» дигән гыйбарә урынсыз яңгырый, ә икенче яктан, дәреслек авторлары Баку һәм Дербентны



● Мөхәммәд Ходабәндә чоры тәңкәсе.



● Сефевидлар гербы.

русларга бирү тәкъдиме турында дәшми, ягъни дөреслекне әйтеп бетерми.

Шунысы кызык, Мөхәммәд Ходабәндә ягыннан (1578-1587) Баку һәм Дербентка ташлама ясавы турындагы мәсьәлә рус тарихчылары тарафыннан җентекләп шәрехләнгән. Аерым алганда, Тимур Кораев үзенең Сефевид – Россия мөнәсәбәтләре турындагы күләмле мәкаләсендә әлеге мәсьәләне төгәлрәк һәм тулысынча аңлатып бирә. Шаһ Мөхәммәд Ходабәндә һәм патша Федор Иванович Госманлы дәүләтенә каршы бергәләп каршы чыгарга карар кыла, Каспий буе җирләре госманлылардан тартып алынганнан соң, Россиягә Баку белән Дербентны тапшыру турында килешәләр. Ә 1588 елда патша Федор, сөйләшүләрне тәмамлар өчен, Казвин шәһәренә Г.В. Васильчиковны җибәрә. Бу вакытта Мөхәммәд Ходабәндә бәреп төшерелә, тәхеткә аның улы шаһ Аббас I (1587-1629) күтәрелә. Җ.Айдогмушоглу һәм Т.Кораев та аның Г.Васильчиков белән очрашуы турында бер үк фактларны яза, әмма икенче автор рус патшасының Ширван өлкәсенә дә дәгъва кылуын һәм илченең «яшь шаһ»ка Баку һәм Дербент белән бергә Шемаханы да «бүләк итү» таләбен куюын билгеләп үтә.

1592 елда шаһ Аббас I Мәскәүгә Гаджи Искәндәр җитәкчелегендә, ә 1593 елда Гаджи Мөхәммәд җитәкчелегендә делегацияләр җибәрә. Ике делегация дә корал һәм хәрби җиһазлар белән тәэмин итүләренә ирешергә омтыла. Ә рус патшалары Федор Иванович һәм Борис Годунов 1593, 1595 һәм 1598 елларда илчеләрен «сәүдә максатлары белән» җибәрәләр. Н.Сөләйманов бу миссияләрне тасвирлаганда, Каспий буе территорияләре турындагы мәсьәләгә XVII гасыр башы турында сөйләгәндә генә игътибар итә: «Шаһ Аббас I, 1603 елның августында Мәскәүгә үз илчесе Лачын бәкне җибәрде, Россиядән Госманлы дәүләте белән башланган сугышта хәрби ярдәм сорады. Ә Борис Годунов, Сефевидлар сараена Ярославскийны җибәреп, шаһ Аббас I госманлыларга каршы сугыш башласа, Россия алар белән тынычлык килешүе төземәячәк, дигән вәгъдәне үз өстенә алды. Патша, җирле феодалларның Госманлыларга ярдәменә комачаулау өчен, Дагыстанга гаскәр җибәрү белән канәгатьләнә. Шулай итеп, Мәскәү сефевидлардан Дербент, Баку һәм Шемаха шәһәрләрен алырга ниятли». Димәк, тарихчының фикерләре турыдан-туры булмаса да («соңга калу» белән) Җ.Айдогмушоглу һәм Т.Кораев ачыклаган фактларны тулыландыра.

Хәзер фактны аңлатуга күчик. Барыннан да элек, Баку һәм Дербентны басып алу идеясе Россия тышкы сәясәтенә Петр I (1682-1725) тарафыннан кертелгән, дигән раслау хаталы (шактый киң таралса да) булып чыга. XVI гасыр азагында шаһ Мөхәммәд Ходабәндә Дербент һәм Бакуны Иван IVкә тапшырырга вәгъдә итә, бу мәсьәлә 1589-1590 елларда актуальлек ала һәм шуннан соң үз әһәмиятен югалтмый. Башкача әйткәндә, «Кавказ мәсьәләсе» Россиянең стратегик планлаштыруында Казан һәм Әстерхан ханлыкларын басып алу белән бер вектор өстендә каралырга тиеш.

Икенчедән, Россиянең Әстерханны алу белән үк (хәтта параллель рәвештә) Кавказ юнәлешендә хәрәкәт итә башлавы, шулай ук, Каспий буе территорияләрен яулап алу идеясенең Иван IV чорында яки аннан алдарак барлыкка килүен күрсәтә. Әстерхан белән бергә Кавказ ачкычларын яулап алгач, патша хакимияте, Сефевид – Госманлы каршылыгын оста кулланып, бу юнәлештә тайпылуларсыз алга хәрәкәт итә һәм XIX гасыр башында бөтен Кавказга, шул исәптән Азәрбайҗанга да үзенең властен җәелдерә.

Мәскәү Русе белән дипломатик һәм сәүдә мөнәсәбәтләре әле Ширван шаһ, Аккоюнлы һәм Каракоюнлы заманнарыннан ук, 1465, 1475, 1499 елларда ук урнаша, дип саный тарихчылар. Шулай ук, тәбәкта дингез һәм коры юл сәүдәсе киң таралганлыгы да билгеле. М.Альтман язганча, XV гасырның икенче яртысыннан Ширван сәүдәгәрләре, рәсми дипломатик йомыш белән, еш кына «Зур Мәскәү сарае кунаклары булган». Башка тикшерүчеләр мөнәсәбәтләрнең интенсивлыгын да искәртә: «Иван IIIнең Баку, Дербент һәм Шемаха шәһәрләре турында мәгълүматлары бар иде». Яки: «Аккоюнлы хакимнәре Россия дәүләте белән элемтәләрне сакларга тырыша. Аккоюнлы сараена рус дәүләте илчеләре килә иде». 1475 елны Иван IIIнең Озын Гасан (Аккоюнлы) сараена үз вәкилен җибәрүе, ә 1499 елның язында Фәррух Яссәр (ширван шаһ) онычы Мәхмүтнең үз вәкиле Шәхәбдне Иван III сараена җибәрүе төгәл билгеле. Бер сүз белән әйткәндә, инде XV гасырда ук Мәскәү сараенда Азәрбайҗан турында бик яхшы белгәннәр.

Мәскәүлеләр белән якынаю тенденциясенә килгәндә, заманча рус историографиясендә, аның башы дип, 1548 елда Солтан Сөләйман Кануниның Кавказга походын атыйлар. Госманлылар белән көрәштә Сефевид шаһларының нәкъ шул елны Россия хәрби көчен файдалану турында хыялланa башлаулары ассызыклана. Мөгаен, нәкъ шул чорда Мәскәү Русе Кавказны «күзли башлагандыр». Әгәр дә Россиянең Кавказ сәясәтенә «очлы ташлары» XVI гасыр уртасында ук салынган булуын, алай гына да түгел, Казанны яулап алганнан соң түгел, ә иртәрәк, дип гомумласак, ялгышмабыздыр. Россияне Кавказга этәрүдә сефевидларның юл куймаучан һәм үзгәрми торган антигосманлы сәясәте коткы салучы, стимуллаштыручы һәм хәтта катализатор ролен уйный, дигән нәтиҗәгә нигез бирә безгә фактлар. Нәкъ менә алар русларны Кавказга җиңел килә алулары өчен мөһим сәяси алиби тәэмин итә. Ахыр чиктә бу төрки мәдәни ареалда моңарчы күрелмәгән үзгәрешләргә китерә.

Патша Россиясенең XVII гасырда сефевидлар белән союздаш мөнәсәбәтләргә сылтап, Кавказга экспансия эшчәнлегенә күчүе хәтта гади күзгә дә күренә. 1602 елда Сефевид илчеләре Госманлыларга каршы Мәскәү белән хәрби союз турында килешү төзи. Күпмедер вакыт сер итеп сакланган бу документ буенча, патша гаскәрләре Дербенттагы госманлы гарнизонына Тарки шамхалы территориясеннән басып керергә тиеш була. 1604 елда гаскәр башлыгы И.Бутурлин үзенә буйсынган отрядлар белән шамхалы территориясенә керә, шунда 3 ныгытма төзелешен башлый. Бу вакытта госманлылар позициясендә нык торучы Тарки шамхалы Кырым ханлыгыннан хәрби яклау алып, бу ныгытмаларны җимерә, И.Бутурлинны үз җирләреннән куып чыгара. Шуңа да кармастан, 1767 елда төрекләрнең чираттагы походы вакытында шаһ Аббас I рус патшасына кабат Төньяк Кавказ юлын контрольгә алуын һәм Госманлы – Кырым көчләренең һөҗүмен булдырмый калуны сорап мөрәҗәгать итә.

Игътибар белән карасаң, Сефевидлар һәм Россия арасындагы союздаш мөнәсәбәтләрнең ярыйсы ук тотрыксыз, бернәрсәгә нигезләнмәгән һәм шартлы характерда булуын, беркайчан да диярлек ныклы геополитик әһәмияткә ия булмавын күрергә мөмкин. Госманлы – Сефевидлар сугышы контекстында, кирәге чыкканда – килеп чыгып һәм, кирәк булмаганда, лояль сәүдә мөнәсәбәтләренә трансформацияләнүче бу хәрби-сәяси союз ике як тарафыннан да вакытлы партнерлык дип каралган. Чынлыкта исә Сефевидларның Кавказда төп көндәше Госманлы дәүләте түгел, ә бәлки Россия империясе була, ә Госманлыларның Касри-Ширин тынычлык килешүенә кул куюы белән исә (1639) бу көндәшлек аерымачык төс ала. Шаһ Аббас II (1642-1666) ханлыгы чорында Җаек һәм Дон казакларының туктаусыз һөҗүмнәре аркасында мәнфәгатьләр бәрелеше ачыктан-ачык каршылык стадиясенә күчә. Бу вакытта инде патша Алексей Михайлович (1645-1676) боерыгы буенча Терек елгасында һәм Дербент тирәсендә кабаттан ныгытмалар төзү омтылышы башлана.

XVII гасыр башында Россиянең Кавказдагы төп таянычы булган Тарки ныгытмасы патша наместнигы яшәгән шәһәрчеккә әверелә, монда 2000 солдаттан торган даими гарнизон урнаштырыла, шулай ук, бирегә шактый санда рус, әрмән һәм кабардин гаиләләре күчерелә. 1635-1645 елларда Терекның уң як ярындагы Сунжен крепосте ныгытыла һәм административ үзәк шунда күчерелә. Рус гражданлыгын кабул иткән кабардинлылар (алар белән кенәз Муцал Черкасский, Илдар морза һәм башкалар командалык иткән) Сунжи тирәсенә урнаша. Шул ук елларда кахетин хакиме Теймураз, Сефевидларга каршы көрәштә патшаның ярдәмен сорап, Гейста (гейсада) ныгытма төзүне сорый. Бу патша черкесларның Сефевидлар белән элемтәләрен өзәргә һәм Россиядән Грузиягә ярдәм җибәрүне җиңеләйтергә тиеш була. Теймураз белән Алексей Михайловичның якынаюы Грузиянең Кавказга карата оккупация планнарын ачып бирә.

Урыс гаскәрләренең төньяк чикләрдә көчәюеннән, казакларның һөҗүменнән куркып, шаһ Аббас II өлкә башлыкларына хәрби төзелешләрне ныгыту, яңа каравыл пунктлары урнаштыру һәм бу урыннарга укчылар китерү турында фәрман бирә. 1650 елда Кубань казаклары Ширван һәм Дагыстан сәүдәгәрләре кәрванын басып ала һәм товарларын талый. Ширван бәге Хөсрәү хан йөкләренә дә талау һөҗүме ясала. Хан Әстерхан сардарын (наместнигын) казакларга ярдәм итүдә гаепләп, компенсация таләп итә.

«Әгәр кирәк булса, Тарки белән Әстерханны җир белән тигезлим. Шаһ бу хакта белә, әгәр бу хәл тагын да кабатланса, без тиешле чаралар күрәчәкбез», – дип яза ул. Чынлыкта шаһ Аббас II не казакларның талау һөҗүмнәренә караганда Сунжа крепостенең ныгытылуы һәм рус гаскәрләренең шунда урнашуы ныграк борчый. Бирегә Дарьял ашуын контрольгә алу максатыннан килеп урнашкан кабардин отрядлары якында яшәүче Сефевид гаскәрләренә еш кына һөҗүм итә, аларны куркуда тота, аларны бу пункттан куып чыгару максатын куялар. Шуңа күрә, килеп чыккан хәлдән файдаланып, ул Хөсрәү ханга Терек һәм Сунжа елгалары буендагы урыс ныгытмаларын җимерергә боерык җибәрә. 1653 елда Азәрбайҗан һәм Дагыстан хәкимнәренең берләшкән гаскәрләре Сунжа һәм Дербент астындагы берничә кечкенә ныгытманы җимерә, ләкин шаһ Аббас II, Россия белән мөнәсәбәтләрне бозмас өчен, Терек елгасындагы ныгытмаларга кагылмаска куша.

Шулай итеп, Мөхәммәд Ходабәндәнең Дербент һәм Бакуны «патша кардәшенә» бүләк итәргә вәгъдә бирү факты аңа кадәр һәм иртәрәк булган хәлиткеч вакыйгаларның бөтен спектрына ачыклык кертә. Бу ачыклык Казан белән Әстерханны басып алу һәм «Кавказ сәясәте» арасындагы өзлексез бәйләнешне исбатлый, киңәя барып, Нугай Урдасы һәм Кырым ханлыгы өчен дәвам иткән туктаусыз көрәшне дә үз эченә ала.

Низамеддин МУСТАФА,
Азәрбайҗан публицисты.

Үзгә фикер

Солженицын хатасы

(Советлар Союзы төзелүгә – 100, җимерелүенә 31 ел)

1994 елның май-июль айларында атаклы язучы, Нобель премиясе лауреаты Александр Исаевич Солженицын хатыны Наталья Светлова, олы улы Ермолай белән Америка Кушма Штатларыннан Россиянең Магадан аэропортында төшеп, «Владивосток-Мәскәү» поездында, зур тимер юл станцияләрендә туктый-туктый, халык белән сөйләшеп, журналистларга интервью биреп, ике ай буе кайтты. Аның элек Сталин лагерьлары тупланган, шул исәптән үзе дә ГУЛАГ тоткыны булып торган Себер киңлекләренә карап, хозурланып, үз башыннан узганнарны тагын бер тапкыр исенә төшереп кайтасы килгәндер инде.

иде соң? СССР – супердержава, бөтен урыс җирләрен җыеп, тотып торган бөек империя иде бит! Солженицын Советлар Союзын саклап калу өчен көрәшәсе урында, киресенчә, аңа каршы көрәште, яккамады. Союзны җимерүгә эмигрант урыс язучылары үзләре дә зур өлеш кертте. Горбачёвның реформалары СССРны үзгәртеп корса да, ул урысларның бөек державасы рәвешендә саклапып кала дип ышандылар, ахры. Ләкин һич тә алар уйлаганча килеп чыкмады. Советлар Союзын ахыр чиктә сепаратистлар, милләтчеләр таратты. Урыслар да «ярык тагарак» янында утырып калды. СССР таркалу беренче чиратта урыс халкы өчен катастрофа булды.

Заманында шулай, Себер буйлап Кытай Халык Республикасы лидеры Мао Цзэдун 1949 елның декабрь аенда Иосиф Сталинны 70 яшьлеге белән котларга дип, Мәскәүгә поездда килгән иде.

Аннары 2002 елның 20-24 августында Корея Халык Демократик Республикасының (Төньяк Корея) җитәкчесе Ким Чен Ир бронепоездда Россиягә – Владивостокка кадәр сәяхәт ясаган иде, анда ул 23 август көнне РФ Президенты Владимир Путин белән очрашып сөйләште.

А.Солженицын Россиягә кире кайткач, аңа яшәү һәм иҗат итү өчен барлык шартлар да тудырылды. Хәтерлисездер, 90 нчы елларда берара «Россия» дәүләт телевидениесенең төнге уникедә башлана торган тапшыруында Солженицын сөйли иде. Шул тапшыруларның берсендә язучы авызыннан «Төньяк Казахстан – ул Россиянең тарихи җирләре» дигән сүзләр ычкынды. Икенче көнне ул тапшыру көндезге программада кабатланырга тиеш иде, әмма шаккатмалы хәл – ул эфирга чыкмады. Ни өчен? Чөнки Казахстанның беренче Президенты Нурсолтан Назарбаев Россиянең ул чактагы Президенты Борис Ельцинга шалтыратып, шовинистик тапшыруны туктатырга үтенгән, диделәр. Алдан күрүчән, зирәк Назарбаев озакламый Казахстанның башкаласын Алма-Атадан Астанага күчерде дә куйды. Ул да, казахның башка түрәләре дә Төньяк Казахстан Россия Федерациясенә кушылыр дип курыкты, чөнки анда урыслар, казахка караганда, күбрәк.

Чыннан да, монда урынлы сорау туа. Солженицын шулай сөйләгәч, язучы ни өчен Советлар Союзын ташлап киткән

Урысларның милли мәнфәгатьләрен, телен, мәдәниятен, мәгарифен, фәнен, халык традицияләрен саклап килгән бөек дәүләт җимерелде, егерме биш миллион урыс тарихи Ватаны Россиядән читтә аерылып калды. Бу хәл, һичшиксез, урыс милләте өчен зур фаҗига иде.

А.Солженицын СССРга каршы язды, Горбачёв реформаларын якламады шикелле. Уртак Ватаныбызны саклап калу өчен ни эшләде ул, йә әйтегез?! Россиягә кайткач, бөекдержавачылык шовинизмына нык басым ясады, аны игътибар үзәгенә куйды, үзенең шовинистик рухын ачып салды ул. Россия матбугатында 1990 елның 18 сентябрендә («Комсомольская правда», «Литературная газета») А.Солженицынның «Как нам обустроить Россию?» дигән публицистик эссесы бастырылды.

«Төньяк Казахстан – урыс җирләре», имеш. Россия империясе вакытында Казахстан бөтенләй юк иде, Төркестан дип атала иде ул җирләр. Рим императорлары әйткән «бүлгәлә һәм хакимлек ит» шигаре астында СССР 70 елдан артык исән-сау яшәде. Әгәр туксанынчы еллар башында ахмак либераль урыс демократлары котырмаган, үрчемәгән булса, тагын җитмеш ел яши иде әле Советлар иле. Көнбатыш Европа һәм АКШ киңәшчеләрен тыңлап, демократлар СССРны юк итте. Аның каруы, тиздән көнбатыш дошманнар Россиягә каршы Европа Союзын оештырды. ЕС бүген 27 дәүләтне берләштерә. Искә төшерәм, СССР исә 15 союздаш республикадан гына төзелгән иде. Аерма зур, әйеме?

Илһам ФӘТТАХОВ.

Чуаш теле һәм

«Мәдәни җомга» газетасында (09.12. 2022) «Борынгы бабаларыбыз кайдан?» атлы язма дөнья күрде. Ул профессор Марсель Бакировның яңа китабы турында. Мәкалә авторы – тарих фәннәре докторы Фаяз Хуҗин. Тел гыйлеме белән кызыксынмаган укучы өчен «р», «з» тартыклары, яисә кайсыдыр гасырда кемнең ничек сөйләшүе турында сүз куерту әллә ни кызык та түгелдер. Ә Нурихан Фәттахның да шушы өлкәгә кагылышлы язмасы бар. Ул моңа кадәр беркайда да басылмаган. Бер өзеген сезгә тәкъдим итәм.

Руфина ФӘТТАХОВА,
республиканың атказанган табибе,
медицина фәннәре кандидаты.

Чуаш (чуваш) теле төрки телләр семьясына карый, ләкин бүтән төрки телләрдән бик нык аерыла. Бу хакта академик Б.А.Серебренников та: «Чуаш телен өйрәнгәндә үзеннән-үзе: мондый үзенчәлекләр нинди сәбәпләр аркасында барлыкка килгән, тарихта чуаш халкының чыгышына кагылышлы берәр төрле серле нәрсә юк микән, дигән сорау туа», – дип язган. Башка галимнәр дә бу хакта шундый ук фикер әйтә. Чуаш телчесе Н.А.Андреев: «Чыгышы буенча төрки булган чуаш теле, шулай да, төрки телләрдән шулкадәр нык аерыла – башка төрки телләрдә сөйләшүчеләр өчен ул аңлашылмый», – ди.

Чуаш теленең менә шундый «серле» һәм «аңлаешсыз» булуын күз алдында тотып, кайбер галимнәр чуаш телен чыгышы буенча фин-угор дип, ә чуашларны исә төркиләшкән фин-угорлар дип исәпләгән. Бу теорияне аеруча академик В.В.Радлов яклап чыккан. Чуаш тел гыйлеменә нигез салучы Н.И.Ашмарин моңа каршы килгән. Чуашларны ул чыгышлары буенча төрки дип, алай гына да түгел – Идел буе болгарларының бердән-бер варислары дип исәпләгән.

Чуаш теле һәм чуашларның килеп чыгышы турында менә шул рәвешчә йөз елдан артык бәхәс бара. Соңгы вакытта бу бәхәс яңадан көчәйде. Бәхәс, чуаш теленнән бигрәк, болгар теле һәм Болгар мирасы тирәсендә бара. Татар галимнәренең күпчелеге: чуашлар төркиләшкән фин-угорлар дигән карашны яклый. Чуаш галимнәре исә: чуашлар бик борынгы төркиләр һәм алар Идел буе болгарларының турыдан-туры варислары дигән карашны алга сөрә.

Бу бәхәснең сәбәпләре кайбер галимнәрнең теге яки бу фактларны дөрес аңламавына яисә үзләренчә генә аңлавына кайтып калмый. Бәхәсне тудырган һәм аны туктаусыз кыздырып торган сәбәпләр тирәндә ята. Моның тамыры барыннан да элек һинд-европа тел гыйлеменең теоретик карашларына барып тоташа. Чуаш теле проблемасының әлегәчә хәл ителмәве ул баба тел, генетик туганлык, структур туганлык кебек теорияләрнең мәгънәсезлеген һәм бернинди практик әһәмияткә яраклы булмавын күрсәтүче дәлилләрнең берсе булып тора.

Алтай теленең үзендә шулай ук бер төрле телләр элегрәк, икенче төрле телләр соңрак барлыкка килгән, имеш. Мәсәлән, Алтай семьясында монгол телләре борынгырак, төрки телләр – соңгырак, яңарак дип исәпләнә. Ләкин төрки телләр семьясындагы телләр дә бер үк вакытта барлыкка килмәгән. Чуаш теле, имеш, барлык төрки телләрдән элегрәк дөньяга килгән. Шуңа күрә дә, имеш, чуаш телендә иң борынгы төрки теленең архаик формалары сакланып калган.

Алтаистика белгече Г.Рамстедт нәкъ менә шундый фикер әйткән. Чуаш теле турында ул: «Бу тел бик күп борынгы үзенчәлекләрне, шул исәптән, -З, -Ш урынына -Л, -Р кулланыну саклап калган, шуның өстенә ул бүтән төрки телләргә бәйсез, мөстәкыйль рәвештә үскән. Болгар-чуаш теле 900-1300 елларда югары культура теле булган», – дигән.

Бүгенге чуаш галимнәре менә шундыйрак фикерләрне бик теләп кабатлый һәм чуаш теленең иң борынгы төрки тел булуын исбатлауда әлеге фикерләр төп дәлил буларак хезмәт итә. «Чуаш теленең хәзерге торышы аның гаять дәрәҗәдә борынгы чорларда барлыкка килүе турында сөйли», – ди М.Р.Федотов.

Без чуаш теленең «гаять дәрәҗәдә борынгы чорларда» барлыкка килүен инкяр итмибез, чөнки чуаш теле генә түгел, дөньядагы барлык телләр дә «гаять дәрәҗәдә борынгы чорларда» барлыкка килгән дип исәплибез.

Шулай да, ничек һәм нәрсәгә таянып исбат итәләр соң алар мондый фикерне? Г.Рамстедт әйткәнчә, төрки -З һәм -Ш урынына чуаш телендә -Л, -Р кулланыла икән. Бөтен дәлил менә шул. «Тарихи фонетика» буенча бу болай булып чыга: Л һәм Р тартыклары борынгырак, З һәм Ш тартыклары соңгырак дигән сүз. Л һәм Р тартыкларының борынгырак булуы нәрсәгә нигезләнеп исбат ителә соң? Моның нигезе шул: монгол телләренә «Р»ләштерү һәм «Л»ләштерү хас, ягъни төрки телләрдә -З, -Ш тартыклары кулланылган очракта, монгол телләрендә -Л һәм -Р тартыклары кулланыла. Монгол телләре исә Алтай семьясында иң борынгы исәпләнелә. Тагын сорау: ник? Чөнки монгол телләренә «Р»ләштерү һәм «Л»ләштерү хас. Төрки телләр арасында бары чуаш телендә генә «Р»ләштерү һәм «Л»ләштерү сакланган. Димәк, чуаш теле барлык төрки телләрдән борынгырак. «Тарихи фонетика» теориясенең фәннилек дәрәҗәсе менә шуннан гыйбарәт.

-Л, -Р тартыкларының -З, -Ш тартыкларына караганда борынгырак булуын исбатлау өчен гадәттә чуашча «кыз» ХЕР сүзе белән татарча КЫЗ сүзен чагыштыралар. Кайберәүләргә КЫЗ сүзе ХЕР сүзеннән үзгәргән булып тоела. Ләкин әлеге сүзләрнең кайчан, кайда, ничек барлыкка килүен беркемнең дә исбат итә алганы юк һәм андый кеше табылмас та. ХЕР үзенә башка, КЫЗ үзенә башка сүз булырга мөмкин.

Аннан соң, әйтик, татар телендә -З, -Ш тартыклары кулланылган урында чуаш телендә -Л, -Р тартыклары куллану бернинди закончалык, бернинди туганлык турында сөйли алмый. Татар теле үзенә башка тел һәм аның авазлар составы үзенә башка. Чуаш теле шулай ук кендеге белән татарга бәйләнмәгән – ул шулай ук аерым, мөстәкыйль тел. Ике телдәге тартыкларны чагыштырып, шуларның берсен әүвәлгерәк, икенчесен соңгырак дип игълан итү бернинди логикага туры килми. Чыннан да, кайбер галимнәр, -Л, -Р тартыклары түгел, киресенчә -З, -Ш тартыклары борынгырак дип исәпли. Мәсәлән, Б.А.Серебренников чуашча ХЕР сүзе татарча КЫЗ сүзеннән үзгәргән дип фикер йөртә. Өченче бер тюрколог

аның борынгылыгы

– А.М.Щербак тартыкларның үзгәрүен бөтенләй башкача, үзенчә күз алдына китерә.

Шулай итеп, тавык элегрәк барлыкка килгәнме, әллә йомыркамы дигән сорауга беркем җавап бирә алмады һәм аңа җавап бирү мөмкин дә түгел.

Чуаш теленең үзенчәлекләре

Төрки телләр белән чагыштырганда, чуаш телендәге сузыкларның әйтелеше бик тотрыксыз. Моны чуаш галимнәре үзләре дә таный. М.Федотов бу хакта болай ди: «Борынгы төрки телдәге О сузыгы урынына чуаш телендә кимендә биш сузык килә ала, шул ук вакытта татар телендә У сузыгы гына кулланыла».

Татар телендә беренче иҗек А сузыклы булса, чуаш телендә әлеге А сузыгы Уга әйләнә.Татарча АЛМА, чуашча УЛМА, татарча АРПА, чуашча УРПА, татарча АТ, чуашча УТ, татарча МАЛ чуашча МУЛ.

Татарча У сузыклы булган беренче иҗек чуаш телендә, киресенчә, А сузыклыга әйләнә. Татарча ИР, чуашча АР, татарча Идел, чуашча Атыл.

Чуаш телендә кайбер зат алмашлыклары һәм гади саннар икешәр, өчәр вариантта кулланыла. Мәсәлән, «мин» ЭПЕ, ЭП, «син» ЭСЕ, ЭС, «бер» ПЕР. ПЕРЕ, ПЕРРЕ, «ике» ИК, ИКЕ, ИККЕ, «өч» ВИС, ВИСЕ, ВИССЕ. Фонетик тотраксызлык Чуаштанның башкаласы Чабаксар исеме әйтелешендә дә күренә. Бу шәһәр чуашча ШУПАШКАР, ШАПАШКАР, ШӘПАШКАР, ЧУПАКСАР, ШАБАШКАР, ШОПАШКАР, ЧОБАШКАР вариантларында кулланыла.

Ни турында сөйли соң бу тотрыксызлык? Әгәр телдә еш кулланыла торган иң гади сүзләр дә ныгып, нормалашып җитмәгән икән, моны инде бер дә телнең борынгылыгы, архаиклыгы дип атап булмый. Борынгы, архаик телдәге сүзләр катып калган булырга, үзгәрмәскә һәм бер генә вариантта кулланылырга тиеш иде сыман. Димәк, мондый тотрыксыз әйтелешле сүзләр чуаш теленең бик борынгыдан килә торган үз сүзләре түгел, алар – алынма сүз. Алар, чит телләрдән алынып, чуаш теле әйтелешенә яраклаштырылган, дөресрәге әле һаман яраклаштырылып җиткерелмәгән.

Чуашның кайбер сүзләрен төрки сүзләр белән чагыштырып, аларның уртак «баба тел» праформасын табарга тырышу гомумән мөмкин нәрсә түгел. Мәсәлән, татарча БАГАНА (столб) чуашча ЙУПА дип атала. БАГАНА белән ЙУПАны иң оста компаративистлар да тарихи фонетика нигезендә аңлата алмас иде.

Соңгы мисалларга нигезләнеп: монголлар кебек үк, чуашлар да төркиләргә (бу очракта татарларга) «генетик» туган түгел, чуаш теле чыгышы буенча төрки түгел дигән фикер әйтәбез.

Чуаш телендә күплекне белдерү

Чуаш теле -ЛАР рәвешендәге күплек күрсәткече булмаган бердәнбер төрки тел. Чуаш телендә күплек төшенчәсе САМ яисә СЕМ иҗекләре ярдәмендә белдерелә. Шулай итеп, бик кызык хәл барлыкка килә: кайбер галимнәр исәпләгәнчә, чуаш теле төрки телләрнең иң борынгысы, иң әүвәлгесе, ләкин башка төрки телләргә хас -ЛАР анда юк. Ничек болай булган?

Чуаш теленең болгар һәм хазар телләренә мөнәсәбәте

Кайбер телче галимнәр болгар һәм хазар телләре бүгенге чуаш теленә охшаш булган дигән фикер әйтә. Мондый фикерне раслау өчен Болгар кабер ташларындагы һәм Дунай буе болгарлары телендәге кайбер сүзләр мисал итеп китерелә.

Мәсьәләне ачыклау өчен без яңадан чуаш теле үзенчәлекләренә игътибар итмәкче булабыз. Чуаш теленең сузыклары гына түгел, тартыклары да башка төрки телләрдәге тартыкларга охшамаган. Мәсәлән, чуаш телендә Q тартыгы юк. Татар телендә Q тартыгы белән әйтелә торган сүзләр чуаш телендә Х тартыгы белән әйтелә. Бу яктан ул тува, хакас һәм якут телләренә охшаган, ди чуаш теле галиме М.Федотов.

Чуаш теленең тартыкларга кагылышлы икенче бер үзенчәлеге шунда: башка төрки телләрдә (мәсәлән, татарда) В тартыгы кулланылган очракта, чуаш телендә П тартыгы кулланыла. Ягъни чуаш телендә В тартыгы гомумән юк. Мәсьәләгә бу яктан караганда, чуаш теле хакас, шор һәм Чулым төркиләре теленә тугандаш, ди чуаш галиме М.Федотов. Аның фикеренчә, П тартыгы В тартыгына караганда әүвәлгерәк икән.

Чуашларны борынгы болгарларның варислары дип исбат итәргә тырышучы галимнәр өчен иң күңелсезе шунда – чуаш теле ярдәмендә Болгар-Булгар дип тә, Биләр дип тә әйтеп булмый. Чуашча Болгар – ПАЛКАР дип, Болгарның башкаласы Биләр шәһәре ПҮЛЕР дип атала.

Тарихи чыганакларның берсендә дә ПАЛКАР дигән сүз телгә алынмый. Грек-латин, гарәп-фарсы, әрмән чыганакларында, рус елъязмаларында бары БОЛГАР турында гына сүз бара. Ибн Фадланда бу сүз БЛГАР дип, Ибн Рустәдә, Гардизидә һәм Бакридә БЛКАР дип язылa. Рус елъязмаларында, Кий походы чорында: «Таже на Волжские и Камские Болгары ходив и победи», 986 елда: «Приидоша Болгары веры Бохъмичи», диелә.

Мәхмүд Кашгарый монгол яуларыннан ике йөз еллар элегрәк яши. Аның сүзлегендә күп төрле төрки кабиләләр телгә алына, аларның тел үрнәкләре теркәлә. Ләкин М.Кашгарый чуаш телен яисә аңа охшаш телне белми. М.Кашгарый теркәгән тел фактлары болгар-чуаш, хазар-чуаш теорияләренә тулысынча каршы килә. Мәсәлән, кайберәүләр ЧУАШ сүзен САВИР-СУВАР сүзеннән чыгара. М.Кашгарый язганча, суварлар болгарлар, кыпчаклар, бәҗәнәкләр белән якын тугандаш. «Башка төрки телләрдә АЙАК диелсә, кыпчак, йәмәк, сувар, болгар телләрендә АЗАК диелә», – дип яза М.Кашгари. Әлерәк кенә күреп киткәнчә, чуаш телендә «аяк» АЗАК та, АЙАК та түгел, – УРА. «Сүз башында М хәрефен угызлар, кыпчаклар һәм суварлар Б хәрефенә әйләндерә. Мәсәлән, төрекләр МӘН бардым дисә, алар БӘН бардым», дип яза Х гасыр галиме. Һәм менә шушы сүзләр генә дә СУВАРның чуаш була алмавын тулысынча исбат итә булса кирәк.

1986 ел.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

31 декабрь (шимбә). ***Җөмәдел ахир аеның 8 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 11.50 сәгатьтә калка, 2.18 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.06 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

Алоэ ширбәте

Барлык төр ангина, коклюш, бронхит, үпкә ялкынсынуы вакытындагы ютәлне йомшарту өчен, алоэ ширбәте кулланалар. Киң авызлы пыяла савытның яртысына кадәр вакланган алоэ яфрагы салып, шикәр белән күмәләр, марля белән каплыйлар. 3 көн төнәткәч, сөзәләр. Көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр аш кашыгы кабалар.

1 гыйнвар (якшәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 9 нчы көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 12.50 сәгатьтә калка, 3.03 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.07 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Алмалы бәрәңге

Уртача зурлыктагы алма, суган, бәрәңгене 1 л суга салып, кайнатып чыгаралар да, су яртылаш кимегәнче пешерәләр. Көненә 3 тапкыр 1 әр чәй кашыгы кабу хроник ютәлне баса.

2 гыйнвар (дүшәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 10 нчы көне. 11нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 13.01 сәгатьтә калка, 4.29 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.08 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уяныргa мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

3 гыйнвар (сишәмбе). ***Җөмәдел ахир 11 нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 13.17 сәгатьтә калка, 5.54 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.09 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Иммунитетны ныгыту

Иммунитетны ныгыту өчен көн саен гөлҗимеш төнәтмәсе эчәргә, 1 чәй кашыгы кызыл миләш ашап куярга, 1 аш кашыгы үсемлек маена турап салынган

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

ярты баш суган ашарга кирәк – бернинди салкын тию дә янамаячак. Көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, кишер согы эчү дә файдалы.

4 гыйнвар (чәршәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 12 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 13.39 сәгатьтә калка, 7.15 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.11 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Сырганак сихәте

Сырганак җиләге аскорбин, шәраб, кузгалак, гәрәбә кислоталарына бай. Күз күреме начарланганда, катаракта башланганда, түбән кислоталы гастрит вакытында, хроник эч кипкәндә болай дәвалану файдалы: 2 аш кашыгы җиләкне төеп, стакан ярым кайнар суга салалар, җылы урында 1 сәгать төнәтәләр, сөзәләр һәм көненә 3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, яртышар стакан эчәләр. Авитаминоз, азканлылыкны дәвалау, химия терапиясе курсыннан соң хәл кертү өчен, 3 өлеш суга 1 өлеш сырганак согы кушып, ашаганнан соң, көненә 2-3 тапкыр 2 шәр аш кашыгы эчәләр.

5 гыйнвар (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 13 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 14.13 сәгатьтә калка, 18.28 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.13 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Ревматизмнан дәва

Кечкенә киндер капчыкка солы салып, суда кайнатып чыгаралар. Кайнар килеш, авырткан урынга куялар. Тәмам сихәтләнгәнче, берничә тапкыр шулай кабатлыйлар.

6 гыйнвар (җомга). ***Җөмәдел ахир аеның 14 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 15.01 сәгатьтә калка, 9.26 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 7.15 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Катламлы күптермә

1 кг бәрәңге, 0,5 кг тавыкның түш ите, 2-3 кишер, 2-3 баш суган, 1 стакан пешкән фасоль, уылган сыр, әз генә атланмай, майонез яки каймак кирәк. Калын төпле кәстрүлгә атланмай салып, түгәрәкләп туралган бәрәңге тезәләр, өстенә туралган түш итен тигезләп җәяләр, аннан соң божралап туралган суган, уылган кишер, фасоль, кабат бәрәңге җәяләр, өстенә майонез яки каймак сылыйлар, уылган сыр сибәләр һәм газ мичендә 40 минут пешерәләр. Катламнарның һәркайсына борыч, тоз, тәмләткечләр сибә баралар.

Дөньяда һәркемнән сүз кала

(Остазыбыз Мостафа Ногманның тууына 110 ел)

Сингармонизм кануныа буйсынганга, гаҗәеп йомшак, мөлаем булганга күрә, кушымчаларының сүзләрен математик төгәллек белән модаль төсмерләргә бизи алган татар теленең матурлыгын, шул сүзләрне нинди хәрефләр белән генә яздырырга тырышып аптыратсалар да, тугры динен, кешелекле матур әдәпләрен искә төшереп торуның җаен таба белгән остазлар университетның татар бүлегендә укыта иде. Бүлек үзе тарих-филология факультетының бер группасы булып, ел саен 30 кеше кабул итте, 5 елдан 25-27 ләп кеше тәмамлый иде аны. Факультетның деканы – безне татар морфологиясе аркылы «үзебез болай да беләбез инде, бер кызыгы да калмагандыр», – дип исәпләнгән татар теленең кадерен «мамыкка төреп, бүреккә куеп» сакларга өйрәткән кешеләрнең берсе – Диләрә Гариф кызы Тумашева – Себер кызы иде. «Диләрә апа», – дип дәшергә куша иде ул безгә, минем әти гарип түгел, ә «Диләрә Гарифовна дип әйтеп җиткерә алмыйсыз, безнең телдә шулай дөресрәк», – дия иде ул. Аның тырышлыгы белән, авыл балаларына дөнья күрсәтү өчен, 4 курстагы һәр группа берәр чит шәһәргә барып кайта. Безне Фрунзе белән Алма-Атага алып бардылар. Анда казах, кыргыз филолог студентлары белән аралаштык. Бу авылдан килгән яшүсмергә: без шундый ук адәм балалары, артык һәм ким җиребез юк, дип яшәү өчен мескенлеккә каршы прививка да булды. Укытучыларның күбесе йә сугыштан кайткан, йә сугыш заманында үсеп, белем алган кешеләр. Белем белән тәрбиянең берлегеп үз мисалларында күрсәтә беләләр иде. Бик бай заманалар булмаса да, ел саен һәр студентка фольклор, диалектологик экспедицияләргә чыгып, фәннең халыкның үзеннән җыеп, аны үзенә кайтару алымнарын өйрәтү генә түгел, кешеләр белән үзеңне тоту өчен сабак, мескенлек белән тәкәбберлеккә каршы әдәп дәресләре дә булгандыр.

Марсель абый Бакиров белән Башкортстаннның Дүртөйле районына чыктык. Ул: «Татар бүлегенә кергән кеше җырлый-бии белә, һәр кешедән – өч номер», – дип күрсәтмә бирде. Поездда 3 сәгатьлек концертка оештык – яртысын Марсель абый үзе сөйләп тутыра иде. Экспедициядә көне буе халык арасында эшләп, фольклор җыябыз. «Шул да булдымы эш?» – дип сорап гаҗәпләнүчеләргә җавап бирә алмасак та, тыңлап торырга өйрәндек. Кич белән концерттан кайткач, һәр кешегә берәр тавык, бер шешә кымыз, бер стакан бал ашата. Марсель абыйның Башкорстанда абруе зур, колхоз рәисләре безне бер халыкның ике канаты – татар-башкорт халык дипломатиясенә әзерләп, шулкадәр кадер-хөрмәт күрсәтеп, формалашып килә торган җаныбызга Башкортстанның туганый республика икәнлеген гомер буе танырга өйрәтте.

Бер группадаш кызны башкорт югары уку йортында укучы бер егет «свидание»гә чакырды. Марсель абый: «Чыгып, матур итеп сөйләшеп керәсең, үзем янәшәңдә булырмын. Казан студентлары тәкәббер икән, диярлек булмасын», – ди. Менә сиңа мә!

В.Ленинның «Материализм и эмпириокритицизм» әсәрендә татарларның барысы да диярлек укый-яза белгән, дип тануын безгә Резеда апа Ганиева әйтте. Бу безгә мескенлеккә төшерә торган ситуацияләрдән чыгарга ярдәм итте. Бөтендөнья әдәбияты – көнчыгыш-көнбатышың бер итеп татар әдәбиятының урынын таптырды, аның да «Мир» суыткычында һәр студентка пешереп ашатырга әзер, изеп куйган коймагы, берәр яңа матур кием киеп килсәң, сөендерә белгән комплиментлары бар иде.

Безнең чыгарылыш кичәсенә Финляндиядән килгән татар гаиләсе чакырулы иде. Мөхәммәт абый Мәһдиев: «Тыңлап тор болар сөйләшкәнне, Тукай заманында татарларның теле бу, резервациядә аларда саклаган», – дип әйтте.

● Мәскәү Шәрыкне өйрәнү институтында укыганда, 1950 ел. Уңнан беренче булып утырып тора.

Конспект дәфтәрен икегә бүлеп, хәзер сөйләргә яраклы информацияне – бер ягына, татар филологлары белергә тиешле, ләкин архив, гарәби әдәбиятта гына сакланган информацияне икенче ягына язып барырга, конспектларда һәрвакыт өстәмәләр язып бара торган урын – хашия барын да ул өйрәтте.

Үзе мәһабәт һәм горур кеше булса да, Мөхәммәт абый тәкәбберлекне сөймәде. Дөньялар бераз үзгәреп, трамвайда татарча сөйләшкән өчен авызыңа сукмый торган вакытлар килгәч, Бауман урамында озын күлмәк, зур яулыклар бәйләп подиумдагы кебек йөргән татфак кызларына: «Һиндстан сиерлары кебек йөрмәсәгез булмыймы?» – дип әйткәнен сөйләгәннәре бар. Миңа ул бервакыт киресенчә: «Йөрмә җәй көне шәһәрдә, идән астында үскән бәрәңге сабагы кебек, кайт авылга, кояш күрсен үзеңне», – дигән иде. Ә мин каникулда акча эшләргә дип заводка кергән идем, төнге сменадан кайтып килгәндә очрады.

22 декабрь көнне мине һәм безнең төркемне гарәби Коръән хәрефен танырга, әлифне таяк дип белергә өйрәткән хөрмәтле газиз остазыбыз шагыйрь һәм тел галиме Мостафа Ногман улы Ногмановның тууына 110 ел тулды. Ул Арча районының Кызыл Яр авылында дөньяга килгән. 1951 елда Мәскәүдәге Көнчыгышны өйрәнү институтын тәмамлап, кандидатлык диссертациясен XVII-XVIII йөзләрдәге кульязма рус-татар сүзлекләре буенча яза. Казан университетының фәнни китапханәсендә Шәрык кульязмаларын өйрәнү бүлеге мөдире була, студентларга фарсы һәм иске гарәп язуын укыта. Сугыш ветераны, шагыйрь, күп шигырьләренә бик матур җырлар язылган. Мостафа абый Казанда 1976 елның 4 сентябрендә вафат булды. Мәрасимдә төркем белән без дә катнашкан идек.

Музейда аның үз кулы белән язып биргән фәнни хезмәтенә кушымтасы, «Русско-татарский рукописный словарь П.Рычкова и М.Габдрахманова, составленный в 1740 годах» һәм «Словарь-разговорник, составленный русскими купцами в конце XVII века» атлы китаплары саклана. «Республика Әдәби музеена автордан бер хатирә. 10.11.1975 ел, М.Ногманов». Ачылышына 50 ел тулган әдәбият бүлеге экспонатлары шулай җыйналган булган.

1944 елның 31 декабрендә чыккан «Кызыл Армия» газетасында М.Ногманның «Кайту» шигыре басылган.

Мостафа абый безгә 1 курста гарәп хәрефләрен өйрәтте. Ул безне укытмады, ә өйрәтте. М.Ногман пәйгамбәребезнең «Авырайтма, җиңеләйт», – дигән хәдисендәгечә, бик җиңел итеп хәрефләрне күрсәтеп чыкты. Тактага бер хәрефне

●Мостафа Ногман Якуб Агишев белән. 1956 ел, 1 май.

яза да, бераз каратып торгач, сөртеп ала. Шулай итеп, бер дәрестә 5-6 хәреф өйрәтә. Берничә көннән без ул хәрефләрне истә калдырдык һәм ул безгә күчереп язырга текстлар биреп җибәрә башлады. Язуын бик тиз язсак та, үзебез язганны үзебезгә укырга авыррак. Элекке мәдрәсәләрдә «Язам, язам да, күнче Шаһига барып укытам», – дигән сүз дә булган.

Аннан дәрес бетәргә 10 минутлап вакыт калгач: «Әйдәгез, балалар җырлап алыйк», – дия иде. Үз җырларын гына түгел, лирик моңлы төрле-төрлеләрен. Бигрәк тә үзе башлап, үзе өйрәткән «Күзләрем тик сине эзлиләр» (Рөстәм Яхин көе) бүгенгедәй истә:

Бакчага ямь кергә,
Хуш исләр бөркелә,
Сиреньнәр чәчәккә бөреләнсә.
Син сөйгән сиреньнәр,
Син күргән сиреньнәр —
Күңелемә иң якын бер нәрсә.

Җырларың тыңласам,
Син барны уйласам,
Күңелемне сүрелмәс моң сара.
Канатлар кайрылган,
Юлыбыз айрылган —
Без бергә булырга юк чара.

Мин җырлап юанам,
Гөлләргә күз салам.
Гөлләр дә: юксынма, түз, диләр.
Сызылып таң атканда,
Ал шәфәкъ батканда
Күзләрем тик сине эзлиләр.

Музейда сакланган өч хаты гарәп язуыннан матур, дөрес итеп гамәлдәге шрифтка күчереп язып, галимнәргә һәрчак ярдәм кулын сузган Нәгыймә апа Сабировага язылган: «Хөрмәтле Нәгыймә ханым! Мәүлет көнегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Сез үз гомерегездә мактаулы хезмәтегез белән күпләрнең рәхмәтләрен ишеттегез. Бик күпләрнең язганнары Сезнең ярдәмдә дөнья күрде. Тел, әдәбият тарихында Сез, һичшиксез, матур бер урын алып торасыз. Безнең дусларча теләгебез: сезгә сәламәтлек һәм озын гомерләр насыйп булса иде. Дусларыгыз Мостафа+Фәридә. 2.IV.1969 ел. Шәһри Казан.

Шундыйлар бар,
Йомышы төшкән чакта
Сезне мактый, аннан югала.
Якын дусларыгыз сезнең өчен
Һаман-һаман хәер-догада».

Рәмзия АБЗАЛИНА.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

30 декабрь – 15.00 Шәрык клубында – «Кыш бабайдан хат» Яңа ел тамашасы.19.00 – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
2 гыйнвар – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
3 гыйнвар – 11.00, 14.00 – «Кәҗә, сарык һ.б.» (И.Зәйниев). 18.00 – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
4 гыйнвар – 15.00 Шәрык клубында – «Кыш бабайдан хат» Яңа ел тамашасы. 18.00 – «Болганчык еллар» (М.Галәү).
5 гыйнвар – 12.00 кече залда – «Көл» (К.Митани). 18.00 – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
6 гыйнвар – 12.00 – «Бию пәрие» (И.Зәйниев). 15.00 Шәрык клубында – «Кыш бабайдан хат» Яңа ел тамашасы. 18.00 – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин). 19.00 – «Томан» (Г.Сәгыйтова).
7 гыйнвар – 12.00 – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров). 15.00 – Шәрык клубында – «Кыш бабайдан хат» Яңа ел тамашасы. 18.00 – «Рәшә» (Ә.Еники).
8 гыйнвар – 18.00 – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
13 гыйнвар – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

30 декабрь, 2,3 гыйнвар – Казан хореография училищесы укучылары башкаруында «Снежная королева» спектакле (XIX-XX гасыр композиторлары музыкасы).
4-8, 12,13 гыйнвар – Казан хореография училищесы укучылары башкаруында «Щелкунчик» спектакле (П.Чайковский).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

30 декабрь – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
2 гыйнвар – «Акча бездә бер букча» (З.Хәким).
3 гыйнвар – 12.00 , 17.00 – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).
